ЧӘЧӘК БАЗАРЫ

Бәйрәм алдыннан иң романтик бизнес вәкилләре белән аралаштык

> 7

НИГЕЗ САКЧЫЛАРЫ

Йөздән артык хуҗалыгы булган авылда бүген нибары дүрт йортта биш кеше яши

> 15



ТЫЙНАК КЕШЕ

Язучы, журналист Рәфикъ Юныс турында якыннары һәм хезмәттәшләренең истәлекләре

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 30 (28997) | Җомга | 3 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

Илдар Мөхәммәтҗанов

ПУМАЛА ТОТЫП КУЛГА

БЫЕЛГЫ ТӨЗЕЛЕШ ЧОРЫННАН НӘРСӘ КӨТӘРГӘ?

Ил халкы артык акчасын куяр урын тапкан. Быел күпләр фатир һәм йортын яңартырга җыена икән. Ел башыннан бирле ремонт кирәк-ярагына ихтыяҗ дүрт тапкыр (!) арткан. Росстат белгечләре төзелеш материалларына сорауның да ике тапкыр артуын әйтә. Без элемтәгә кергән җитештерүчеләр исә башка фикердә. Төзелеш материаллары арзанаермы? «ВТ» хәбәрчесе шушы һәм башка сорауларга җавап эзләде.

> 5

Ишетми калмагыз

Мәскәү белән Казан арасын тоташтырачак түләүле М12 автомобиль юлындагы Идел елгасы аша салынучы күпернең яртысыннан күбрәге төзелгән инде. Корылманың 28 терәгеннән 18е тулысынча әзер, монолит эшләре 87 процентка башкарылган. «Автодор» дәүләт компаниясе матбугат хезмәте хәбәренә караганда, уң як ярдан – 436 метр, сул як ярдан 1294 метр озынлыкта күпер түшәмәсе эшләнгән. Эшчеләргә тагын 1630 метр озынлыкта күпер саласы калган. Аның гомуми озынлыгы 3 чакрымнан артыграк тәшкил итәчәк.
Хәзерге вакытта М12 төзелешенең 8 нче этабында юл өчен җир түшәмәсен әзерләү эшләре алып барыла, җәйге төзелеш сезонына материаллар хәстәре күрелә. Биредә эшчеләр яктырткычлар өчен баганалар, чистарту корылмалары, инженерлык коммуникацияләре урнаштыра. Язгы ташуга кадәр ясалма корылмаларда (кечкенә күперләр, су агызу торбалары, терәк стеналар һ.б.) тимер-бетон конструкцияләрне урнаштыру эшен тәгәлләү күздә тотыла.

Казанның 7 нче шәһәр хастаханәсенә Марат Садыйков исеме биреләчәк. Татарстанның элеккеге сәламәтлек саклау министры исемен шул рәвешле мәңгеләштерү турында карар кылынган. Клиниканың баш табибы Артур Делян әйтүенчә, хастаханә коллективы бу карарны бертавыштан хуплаган.
Марат Садыйков хастаханәгә 10 ел дәвамында – 2008 елдан 2018 елга кадәр җитәкчелек итте. Оешма шушы вакыт эчендә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү үзәгенә, шулай ук республикада иң яхшы хастаханәләрнең берсенә әверелде. Исегезгә төшерәбез: Марат Садыйков 29 гыйнварда, 53 яшен тутырып ике көн узгач вафат булды. 1 мартта Татарстан Рәисе сәламәтлек саклау министры итеп Марсель Миңнуллинны билгеләү турында Указ имзалады.

Татарстанда 1,3 меңләп гаилә ана капиталыннан ай саен түләү алып барачак. 150дән артык ата-ана 3 яшькә кадәрге һәр баласына ике һәм аннан күбрәк түләү рәсмиләштергән.
Социаль фондның республикадагы бүлеге матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, 2023 елдан башлап, 3 яшькә кадәрге һәрбер балага (беренче баланы да кертеп) ана капиталыннан түләү бирелә. Моңа кадәр ата-аналар икенче баласы туган очракта гына сертификаттан акча алу мөмкинлегенә ия иде. Гаиләдә 3 яшькә кадәрге берничә бала тәрбияләнсә дә, бер генә түләү бирелде. Татарстанда айлык уртача түләү күләме 11852 сум тәшкил итә.

Ял көннәрендә, Татарстанга циклон үтеп керү сәбәпле, юеш кар явачак. Көндез һава температурасы +1 градуска кадәр җылына. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, 4–5 мартта көндез һава температурасы –2...+1 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә –2...–8 градус.
Синоптикларның башлангыч фаразлары буенча, киләсе атна башында республикада аз гына явым-төшемле, салкынча һава саклана. Көндез –1...–4, төнге сәгатьләрдә –3...–8 градус булачак.

Районнарда ни хәлләр?

Яңа Чишмә

Зирекле авылында тантаналы рәвештә борынгы мәчет ачылды. Гыйбадәт йорты 1903–1905 елларда төзелгән. Шулай итеп, аның таш һәм кирпечтән салынган диварларына – 117 ел. Узган елны биредә эчке төзекләндерү эшләренә керештеләр һәм, барлык эшләр төгәлләнгәч, ул кабаттан авыл халкы өчен үз ишекләрен ачты. Төзекләндерү барышында мәчетнең эчке өлеше элекке халәтенә кайтты, дивар һәм түшәмнәр яңартылды, идән җылытылды. Мәчет ачылышына мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин да килде.
(Татарстан Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте)

Теләче

Олы Кибәхуҗа авылында милли татар аш-суын дөньяга таныткан Юныс Әхмәтҗановка багышланган беренче фестиваль-конкурс узды. Юныс Әхмәтҗановның кызы Фәридә Давыдова катнашучыларны «уңган-булганнар» дип бәяләде. «Таң калдым. Искиткеч һәм барысы да дөрес эшләнгән. Аеруча урамаларны билгеләп үтәр идем. Франциядә аш-су бәйгесендә әлеге төр ризыкка беренче урын бирерләр иде», – диде ул. Язучы, шагыйрә, эшмәкәр Равилә Шәйдуллина үзен Юныс Әхмәтҗановның укучысы дип санавын әйтте. «Татар халкының әдәбияты, сәнгате, моңы һәм туклану культурасы бар. Юныс абый аны дөнья күләмендә күтәрүче иде. Мондый бәйгеләр булса, халык ашлары югалмас», – диде ул.
(«Теләче-информ»)

Кукмара

Әфганда сугыш юлын узган ир-егетләр безнең Күкшел җирлегендә дә бар. Интернациональ бурычларын намус белән үтәгән егетләребез – Нурислам Галимбековны, Рамил Баһаутдиновны, Мәлик Шакировны ил дә, халык та онытмый. Ватанны саклаучылар көне алдыннан авылыбыз җирлегендә сугышчы-интернационалистлар яшәгән йортларга истәлек такталары кую тантанасы булды. Тантанада әфганчылар советы рәисе, җирлек башлыгы, мәдәният хезмәткәрләре һәм мәктәп укучылары катнашты.
(«Хезмәт даны»)

Баулы

Татар Кандызы авылында кышкы Сабан туен оештыру матур йолага әверелде. Инде дүртенче ел рәттән Ватанны саклаучылар көне иртәсендә мәдәният йорты янында авыл халкы күңелле чарага килә. «Ел саен бу бәйрәмне көтеп алалар, үзебез дә күңел биреп әзерләнәбез. Бу бәйрәмдә өлкән яшьтәгеләр дә, мәктәп укучылары да, хәтта кечкенә балалар да читтә калмый», – дип сөйләде мәдәният йорты җитәкчесе Айрат Хөсәенов. Кышкы Сабан туеның иң кызык мизгелләре – уеннар. Кар өстенә каплап куелган чүлмәкне бәйләнгән күз белән эзләп табу гына да ни тора! Сыңар озын чаңгыда йөрү, чанада тартышу, капкага алка кертү – барысы да бәйрәм кунаклары күңеленә хуш килде.
(«Баулы-информ»)

КУНАК АШЫ

Вертолетлар, нефть химиясе, авыл хуҗалыгы продукциясе. Татарстан Таҗикстан белән әлеге һәм башка өлкәләрдә кулга-кул эшләргә әзер. Бу хакта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановчит илгә эш сәфәре барышында әйтте.

Анда ул Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустин җитәкчелегендәге ил делегациясе составында «Россия һәм Таҗикстанның эшлекле һәм инвестицион партнерлыгы» төбәкара хезмәттәшлек буенча тугызынчы конференциянең пленар утырышында катнашты.

Сәламләү сүзендә Михаил Мишустин Таҗикстан белән элемтәләрне ныгытучы төбәкләр арасында Татарстанны да билгеләп үтте һәм Таҗикстан делегациясен Татарстанга «Россия – Ислам дөньясы: Kazanforum» җыенына чакырды.

Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында билгеләп үткәнчә, Татарстан бу ил белән хезмәттәшлекне үстерергә әзер.

– Безне республиканың әйдәп баручы предприятиеләрен Таҗикстан базарына кертү мәсьәләсе кызыксындыра. Бу – вертолетлар, нефть химиясе, авыл хуҗалыгы продукциясе, көнкүреш товарлары, хәләл продуктлар һәм башкалар, – диде Рәис.

Чит илдәге партнерлар белән уңышлы хезмәттәшлек мисалы итеп Рөстәм Миңнеханов КАМАЗның Дүшәнбедәге арадашчысын да атады. Республика башлыгы, ил Премьер-министры тәкъдимен куәтләп, кабул итүче якны «Kazanforum»га чакырды.

– Россия Президенты Владимир Путин указы нигезендә халыкара икътисадый форум федераль дәрәҗәгә чыкты. Бу – безнең республикага ышаныч билгесе һәм бик зур җаваплылык. Таҗикстан делегациясен форумда күреп шат булачакбыз, – диде Рөстәм Миңнеханов.

БАРЫСЫ ДА БЕЗНЕКЕ

Нәтиҗә

Рухлары – сау, үзләре тәртипле булсын. Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгының ел нәтиҗәләренә багышланган утырышында әйтелгән төп фикерләрнең берсе бу. Моның өчен Татарстанда ниләр эшләнгән һәм ниләр эшләнәчәк?

tatarstan.ru

Билгеле булганча, министр Ринат Садыйковны әлеге вазыйфага бу елның гыйнвар аенда гына билгеләделәр. Ягъни коллегия утырышында министрлыкның Тимур Сөләйманов җитәкчелегендә башкарган эшләренә йомгак ясалды. Кайбер санлы күрсәткечләрдән башлыйк. Яшь министрлыкның 2022 елгы гомуми бюджеты 3 млрд сум тирәсе булган. Яшьләр өчен төзелгән 37 объектта 1,7 млрд сумлык ремонт эшләре уздырылган. Быел исә тагын 41 объектны яңартырга ниятлиләр, моның өчен 3 млрд сумга якын акчаны бүлеп куйганнар инде. Моннан тыш, узган ел дәүләт ярдәме белән 1092 яшь гаилә фатирлы булган. Быел исә бу сан тагын да артачак – 2023 елда яшь гаиләләргә акчалата ярдәмне ике тапкыр арттырып, 100 млн сумга җиткергәннәр.

Рәис шелтәсе

Инде 2023 елга куелган төп максатларга күчик. Ринат Садыйков сүзләренә караганда, быел министрлык өчен ике юнәлеш аеруча әһәмиятле. Бүген яшьләрдә ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләүнең һәм аларны кыек юлдан, тискәре күренешләрдән саклауның мөһимлеге турында еш сөйләнә. Министр да быел моңа басым ясалачагын әйтте. Ни рәвешле икәнен генә белә алмадык: Ринат Садыйков сүзен кыска тотты һәм бу мәсьәләгә «Форпост»ның республика үзәге җитәкчесе Тимур Камалетдиновның әйләнеп кайтачагын әйтте. Тимур әфәнденең чыгышыннан аңлашылганча, яшьләрне патриотик яктан тәрбияләү өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакын күтәрергә кирәк. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов исә бу җәһәттән башкарыла торган эшнең мәгънәви ягына аерым игътибар бирергә кушты.

Яшь буынны тискәре күренешләрдән саклауга килгәндә, бу мәсьәлә соңгы арада аеруча актуаль. Коллегиядә исеме телгә алынмаса да, яшьләр арасында популяр булырга өлгергән «Рёдан» хәрәкәте турында да сүз булды. Бу хакта газетабызның 16 нчы битеннән укырсыз.

> **Сан**
>
> Республикада **4** млн кеше яши, шуларның **26,8** проценты – яшьләр. Бу – **1** млн **72** мең кеше дигән сүз.

– Хәзерге вакытта социаль челтәрләрдә яңа «субкультура» турында хәбәрләр еш күренә. Аның эшчәнлеге дә онлайн форматта бара һәм яшьләрне җәмәгать урыннарында агрессив акцияләр уздырырга өнди. Без моңа җавап кайтармый кала алмыйбыз, – диде Ринат Садыйков.

Проблеманы хәл итәр өчен, министрлык формаль булмаган берләшмәләр белән эшли торган комплексы программа булдырачак. Татарстан Рәисе дә бу мәсьәләгә битараф калмады.

– Әгәр бу эшкә хокук саклау органнары кушыла икән, димәк, тиешле эш башкарылмаган, – диде ул Рөстәм Миңнеханов. – Яшьләрнең деструктив берләшмәләргә җәлеп ителүе – Яшьләр эшләре министрлыгы җитәкчелегенең шәхси игътибарын таләп итә торган мәсьәлә. Бүген яшьләр арасындагы бу процесслар социаль челтәрләрдә бара. Без аларның хокук бозу һәм җинаять кылуга омтылышларын да күрәбез. Мондый гамәлләргә чит илләрдән котыртучылар да очрый. Без барысы белән эшләргә тиеш – бу отличниклар да, өчлегә укучылар да – безнең яшьләр. Алар белән эзлекле, системалы һәм нәтиҗәле эш алып барырга кирәк. Татарстанда деструктив берләшмәләрнең баш күтәрүенә юл куярга ярамый. Мондый хәл башка кабатланмасын!

Өметле хәрәкәт

Утырышта әле тагын балалар һәм яшьләргә бушлай психологик ярдәм күрсәтүнең, студентларны тыңлау һәм ишетүнең әһәмияте турында да фикер алыштылар. Татарстан Рәисе яшь буынны авылда калдыру мәсьәләсендә дә эшне көчәйтергә кушты. Моннан тыш, Ринат Садыйков балаларның җәйге ялына бәйле нәтиҗәләр һәм яңалыклар белән таныштырды. Сүз уңаеннан, быел җәй глэмпинг һәм кэмпинг форматындагы лагерьлар проектларын төзи башлаячаклар.

Шулай ук утырышта күп игътибарны «Алдынгылар хәрәкәте» бөтенроссия балалар һәм яшьләр хәрәкәтенә бирделәр. Барлык яшьләрне берләштерергә тиешле яңа хәрәкәткә зур өметләр баглана чөнки. Балалар һәм яшьләргә бәйле күп кенә проблемаларны хәл итәргә булышыр, дип өметләнәләр.

– Бер мәкаль бар: дошманыңны җиңәргә теләсәң, аның балаларын тәрбиялә. Бүген Россиядәге яшьләр сәясәте тулысынча шуңа юнәлтелгән дә инде. «Алдынгылар хәрәкәте» бик вакытлы оештырылды. Татарстанда аны Тимур Сөләйманов җитәкләячәк. Аңа ярдәм итәрсез дип өметләнәм, – диде бу җәһәттән Яшьләр эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе урынбасары Дамир Фәттахов.

Татарстан өчен үз кеше булган Фәттахов республиканы мактарга да онытмады.

– «Алдынгылар хәрәкәте»нә килгәндә, бу юнәлештә Яшьләр эшләре министрлыгы, Мәгариф һәм фән министрлыгы, район башлыкларына берләшеп эшләргә кирәк. Моны һәркайсыбызның җаваплылыгы дип кабул итегез. Татарстан «Алдынгылар хәрәкәте»нең ышанычлы партнеры һәм иң актив катнашучысы булырга тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ТУП КЫНА ТҮГЕЛ

Булганнан файдалана белергә кирәк. Татарстан Волейбол федерациясенең хисап конференциясендә Дәүләт Советы Рәисе, федерация президенты Фәрит Мөхәммәтшин әнә шундый бурыч куйды.

tatarstan.ru

Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университетында узган чарада Фәрит Мөхәммәтшин халык арасында волейболның популярлашуын билгеләп үтте. «Узган елларда Волейбол федерациясе республикада иң яхшыларның берсе булды. Бу – сезнең – тренерларның, хөкемдарларның, һәвәскәр спортчыларның һәм профессиональ уенчыларның, Татарстанда волейбол тормышына өлеш кертүчеләрнең зур казанышы, – диде ул. – Без республика җитәкчелеге һәм шәхсән Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән Спорт министрлыгы, «Зенит-Казан» һәм «Динамо-Ак барс» волейбол клублары җитәкчелеге белән бергәләп нәтиҗәләргә ирешә алдык».

Волейбол федерациясенең 2022 елдагы эше турында иҗтимагый оешманың башкарма директоры Мансур Кәримов сөйләде. Иң зур эшләрнең берсе дип ул Мәктәп волейбол лигасын атады. Әлеге проект 2018 елдан бирле гамәлдә. Мәктәп лигасында 170 уку йортыннан 27 меңнән артык укучы чыгыш ясады. Бездәге тәҗрибәне ил күләмендә дә күрделәр. Бөтенроссия мәктәп волейбол лигасының беренчесендә 60 меңнән артык укучы чыгыш ясады. Моннан тыш, республикада студентлар, ветераннар волейболы үсә, сәнәгать предприятиеләре һәм авыл районнары арасында ел саен турнирлар үткәрелә. Федерациянең башкарма директоры хәл итәсе мәсьәләләргә дә тукталды һәм 2027 елга кадәр Татарстанда волейбол үсеше концепциясен тәкъдим итте.

Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, республикада волейболны популярлаштыру буенча зур эш башкарыла. «Бездә аны массакүләм спорт төрләренең берсе буларак үстерү өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган, – диде ул. – Һәр шәһәрдә, районда, барлык уку оешмаларында спорт заллары, мәйданчыклар бар. Булган мөмкинлектән нәтиҗәле файдаланырга гына кирәк. Моның өчен бушлай спорт секцияләре, түгәрәкләр санын арттырасы, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре эшен активлаштырасы бар. Спорт белән шөгыльләнеп, волейбол уйнап һәм командада күнегүләр ясап, яшьләр һәм балалар урамның һәм интернетның тискәре йогынтысыннан ераклашачак».

ХӘЛ БЕЛЕШҮ

«Татар-информ»

Татарстан хәбәрчеләре Донбасста күргәннәре турында: «Алар матур кием һәм ял түгел, ә су һәм ризык булу турында борчыла».

«Алар исән һәм шуның белән бәхетле». «Татар-информ» хәбәрчеләре Светлана Белова һәм Михаил Захаров, Лисичанскида булып, андагы хәлләрне үз күзләре белән күреп кайтты. Җирле халык ничек көн күрә? Бер атналык сәфәрләре турында алар хезмәттәшләренә сөйләде.

– Без узган елның февраленнән махсус хәрби операция, мобилизация, гуманитар ярдәмгә бәйле бөтен вакыйга һәм яңалыкларны яктыртып барабыз. Баштан ук мин барысын да үз күзләрем белән күрергә теләдем. Кызык булганга гына түгел, ә халыкка анда нәрсә булганны сөйләү һәм күрсәтү өчен. Без бу сәфәрне узган яз ахырыннан диярлек планлаштырдык. Төрле киеныклар булды, фронттагы вазгыять аркасында сәфәр кичектерелеп килде. Анда болай гына эләгеп булмый, әлбәттә, – дип сөйләде «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы баш мөхәрриренең беренче урынбасары Светлана Белова. – Журналистларга анда эшләү җиңел түгел. Җирле халык безгә бик шикләнеп, сагаеп карады. Кулында фотоаппарат, телефон булган кеше күп сораулар тудыра, әлбәттә. Аларны тынычландырырга туры килде. Фотога, видеога төшәргә дә бик сирәге генә ризалашты.

Тетрәнүдән соклануга кадәр. Җирле халык белән аралашуы хакында Светлана Белова әнә шулай ди.

– Без уңайлы тормышка күнеккән, ә андагы халык катлаулы шартларда яши. Су, газ, ут – бернәрсә юк анда. Ләкин бу авырлыкларга да карамастан, алар, шөкер, барысы да яхшы, диләр. Халыкның фикерләве башка төрле. Алар ничек матуррак киенергә һәм кайда ял итәргә дип түгел, ә суны ничек җыярга, кайдан ризык алырга дип борчыла. Алар тынычлык өмет итә, бу афәтнең тизрәк бетүен тели. Кешеләрнең күбесе сугышчан хәрәкәтләрне кайдадыр еракта бара дип уйлый. Чынлыкта, бу без уйлаганнан күпкә якынрак. Россиянең тыныч территорияләрендә яшәүчеләргә моны җиткерү минем төп максатым иде, – ди журналист.

Билгеле булганча, Татарстан Лисичанскига тыныч тормышка кайтырга ярдәм итә. Ә андагылар элегрәк безнең республика турында гомумән берни белмәгән.

– Хәзер анда барысы да диярлек Татарстан, Казан турында сөйли. Аларга килгән ярдәмнең күпчелек өлеше – республикадан. Без рәхмәт сүзләре генә ишеттек, – ди Светлана Белова.

Волонтер, фотограф Мария Ефремованың Лисичанскига инде дүртенче тапкыр баруы икән.

– Лисичанскига беренче тапкыр узган елның ноябрь башында волонтерлар төркеме составында бардым. Мине фотограф һәм машина йөртүче итеп чакырдылар. Заманында мин Казан танк училищесында штаттан тыш фотограф идем. Шуңа күрә миңа сәфәр кызыклы булды. Тик анда барып җиткәч, бөтенләй көтелмәгән хәлләр күрдем, – ди Мария Ефремова. – Башка җиргә барасы идек. Әмма безне бер батальонның медицина взводына китерделәр. Берничә көн дәвамында мин яралыларны коткаручы табибларның эшен күзәттем. Үзеннән дә аларга ярдәм итәсем килде. Казанга кайткач, медицина җиһазлары алу өчен акча җыя башладык, бик күп кеше булышты. Беренче гуманитар ярдәмне алып килгәч, андагы халык бик сөенде. Аннары табибларга «УАЗ» машинасы да илтеп бирдек.

Ләйсән САФИНА

Аулаганчы саклыйсы бар

Куян елының өченче аена килеп кердек. Баксаң, республикада 29 меңнән артык озынколак исәпләнә икән. Күбесе Азнакай, Әтнә, Мөслим районнары урман-кырларында яши. Кама Тамагы, Чирмешән, Чүпрәледә исә алар кимегән. Бу хакта Татарстанның Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының еллык киңәйтелгән утырышында сөйләделәр.

Комитет рәисе Федор Батков сүзләренә караганда, бер үк шартларда эшләүче аучылык хуҗалыкларында төрле нәтиҗәләр күзәтелә. Кайдадыр җәнлекләр һәм кошлар артып тора, кайбер җирләрдә кими. Шуңа да ул хезмәттәшләренә табигать байлыкларына игътибарлы булырга, төзелгән килешүне үтәргә кушты.

– Татарстанда ауларга рөхсәт ителгән кыргый хайваннарның 81 төре бар, аларның икътисадый бәясе 2,5 млрд сумны тәшкил итә. Республикада иректә йөри торган марал һәм тимгелле боланнарның саны 600гә җитә. Кайбер җирләрдә аларны ауларга да мөмкин булачак, – дип сөйләде комитет рәисе.

Аулау дигәннән, республикада Африка чумасын булдырмый калу өчен узган ел 3 меңнән артык кабан дуңгызын юк иткәннәр. Инде ел башыннан 1 мең кабан атылган. Төлкеләр дә читтә калмаган. Котыру чире азмасын өчен, төлкеләр күп йөргән җиргә 1 миллионнан артык вакцина таратылган. Комитет рәисен, төлкеләр авылга килә, шәһәрдә күренә, дигән хәбәрләр дә борчый. Шуңа да ул калдыклар өчен җавап бирүче оешмаларга игътибарлы булырга киңәш бирде.

Федор Батков, быел аучыларның эше җиңеләячәк, дип тә белдерде. Озакламый аучылар өчен мобиль кушымта эшли башлаячак. Соңгы елларда республикада кайбер төр кыргый җәнлекләрнең саны ишәю ау квотасын арттырырга мөмкинлек биргән. 2022 елда республикада 43 меңнән артык рөхсәт бирелгән. Шул ягы да бар: рөхсәтләрне күбрәк бирә башлау сәбәпле, комитет һәм МФЦ хезмәткәрләренә эш арткан. «Шуңа күрә рөхсәт бирүне гадиләштерергә булдык. Быел май аенда аучыларга ярдәм йөзеннән «Охота в РТ» мобиль кушымтасы эшли башлаячак», – диде Федор Батков. Тагын бер яңалык – Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы белән берлектә, сынау рәвешендә, ауга электрон рөхсәт бирүгә күчү күздә тотыла. Тиздән аучылар өеннән чыкмыйча гына бер көн эчендә ауга рөхсәт ала башлаячак.

Аулау гына түгел, сакларга да кирәк. Татарстанда соңгы 4 ел эчендә юлда кыргый хайваннарны бәрдерү очраклары 3 тапкыр арткан. Республикада 2018 елда – 51, 2019 елда – 102, 2020 елда – 129, 2021 елда 150 шундый очрак теркәлгән. Машина йөртүчеләр поши, кабан һәм кыр кәҗәләрен аеруча еш бәрдерә. Узган ел 158 авария теркәлгән, 175 хайван һәлак булган.

Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин комитет эшчәнлегенә уңай бәя бирде.

– Биш ел элек республикадагы хайваннар дөньясын тулыландыру буенча куелган бурычлар акрынлап хәл ителә бара, – диде ул. – Комитетның цифрлы юнәлештәге тәҗрибәсе уңышлы. Кыргый җәнлекләрнең санын исәпкә алу буенча кышкы маршрут комплексы булдырылды, бу яңалык инде үзен эштә уңышлы күрсәтте. Быел кыйммәтле хайван төрләрен аулауга рөхсәт алу хокукына электрон жирәбә салу өлешендә, шулай ук күптән көтелгән мобиль кушымтада аучылык җәмгыятеннән уңай нәтиҗәләр көтәбез.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Әйтеп кенә бактым

Тел кадере

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Радиодан тапшыру бара, татарча дөрес сөйләргә, дөрес язарга өйрәтәләр. Мин моңарчы наданнар рәтендә йөргәнмен икән. Хәер, мин генә түгел, тулы бер буын:

«Яратам моңлы көй тыңларга,
Кил иркәм гармунда уйнарга...» –

дип җырлап үсте. Ә дөресе «гармун уйнарга» икән бит, композитор Әгъзам Фәттах белән бергә «Кил, иркәм, гармунда уйнарга» дигән җырны иҗат иткән шагыйребез Әхмәт Ерикәй дә хата җибәргән. Татар теле буенча гыйлеме шуның хәтле генә булган Әхмәт агаһың. Аны гаепләргә һич кенә дә ярамый. Башкортстанның Өлкәнде авылында крестьян гаиләсендә туган, кышын авыл мәктәбендә укыган, җәйләрен көтү көткән бу егет күпкырлы талант иясе булып бөтен татар дөньясына танылды.

Мондый шәхескә карата бер-бер тәнкыйть сүзе әйтергә тел әйләнми. Әмма, бүгенге тел галимнәре раслаганча, без «гармунда» дип түгел, ә «гармун уйнарга», «скрипка уйнарга», «пианино уйнарга...» дип сөйләргә, язарга тиеш икән.

Эшкә килгәч, бу хакта хезмәттәшем Фәния Әхмәтҗановага да әйттем әле, киңәш тә сорадым. «Галимнәр сүзен тыңлап, мәсәлән, «Фәния төрле уен коралларында: гармунда, скрипкада, пианинода, мандолинада уйный белә» дигән җөмләне «да» кушымчасын төшереп калдырып язсаң, матур яңгырыйммы?» – дидем. Аптырады ул. «Фәния төрле уен кораллары: гармун, мандолина, пианино, контрабас, саксофон уйный белә, дигәч, нәрсә килеп чыга соң ул?» – ди.

Үзем дә аптыраган инде, Фәния җаным, тел галимнәрен дә кимсетәсе килми. Хуҗа Насретдин шикелле: «Синеке дә дөрес», – дип әйтеп, үзебезчә эшләсәк кенә. Һәр нәрсә шикелле тел дә үсеш-үзгәрешләр кичерергә тиеш инде ул. Төрле халыкларның үзара аралашуы, фәнни-техник багланышлар нәтиҗәсендә телләр дә «аралаша», бер-берсенең «хәләнә керә» башлый һәм бу процессны туктату мөмкин дә түгел. Сүз уңаеннан, «процесс» латиннан алынган, «агым, хәрәкәт итү» дигәнне аңлата. Ул күп телләргә ныклап кереп урнашкан һәм аннан арынуның кирәге дә юк. Тел чуплаучы сүзләр аннан башка да җитәрлек. Ә чүпне без үзебез өстерәп кертәбез, телне үзебез кадерсезлибез.

Урыс кардәшләр «Дәүләт телләре турында» законга үзгәрешләр кертү турында закон кабул иттеләр үзе, маладислар. 2025 елның башыннан ук, мәсәлән, «кешбэк», «тренд», «бизнес-коучинг» кебек сүзләр куллану тыелачак. Ә алмашка нинди сүзләр тәкъдим ителәр? Менә монысы – бик четерекле мәсьәлә. Дөресен әйткәндә, олы агай телендә бүгенге көндә саф урыс сүзләре юк дәрәҗәдә аз. Урысларда чит сүзләргә мәхәббәт VI гасырда ук башланган дип беләм. Мәсәлән, инде тел тәмам күнегеп беткән кувшин, янтарь, деревня, пельмени, мойва, сауна, матрац, адмирал, лак кебек сүзләрнең берсе дә урысныкы түгел. Моннан 15 гасырлар чамасы элек башланган һәм бүгенгәчә дәвам иткән бу олы мәхәббәтне Дума кабул иткән бер закон белән генә юкка чыгарып булыр микән? Мөхәммәт ага Мәһдиев әйтмешли, «едва ли». Ул законның ничек, ни рәвешле тормышка ашарга тиешлеге тәгаенләнмәгән. Инде килеп, тыелачак чит сүзләрне алыштырыр өчен русларның тел байлыгы җитәрме? Бу закон дошманнарга бер йодрык күрсәтеп алу булып кына калмасмы?

Урыс кардәшләргә без дә кулдан килгәнчә ярдәм итәрбез анысы, моңа хәтле күп сүзләр бүләк иттек бит инде, рәхәтен күрсеннәр!

Шул ук вакытта үзебез турында да кайгыртыйк, чөнки федераль закон нигезендә без дә телебез байлыгын тагын бер кат барлап чыгарга тиеш булабыз. Ярый әле тел кадерен белүче галим-голәмәләребез бар. Иртәгәне алдан киртәләр өчен Россия законы аларга ике ел вакыт бирде. «Гармунда уйнауны» «гармун уйнау» дип төзәтү өстенә, алар чит сүзләрне алыштырырдай татарча сүзләр дә табарга тиеш. Вперёд, иптәшләр! Сезгә яңа ачышлар юлдаш булсын!

БӘЯЛӘР, СЕЗ КАЯ БАРАСЫЗ?

Инфляция-дефляция мәсьәләләре рәсми җитәкчелекне дә, гади халыкны да гел борчып тора. Миңа бер нәрсә ошый: соңгысы – халык дип атала торган масса – үткән елгы март паникасыннан соң бәяләр күтәрелешеннән үрсәләнми, товар җыеп калыйм, дип ашыкмый башлады. Кулланучылар ваемсызлыгы – бик яхшы нәрсә ул, чөнки бердәм рәвештә кибетләрне штурмлау товар хакын берничә тапкыр күтәрә. Сәүдәгәрләр файда күрә, кулланучылар оттыра. Шуңа күрә бәяләр күтәрелү турындагы фейкларның артында, чынлыкта, сәүдә мафиясе тора. Кесә калынайту өчен вазгыятьне шулар оста файдаланалар.

Уртача инфляция саннары тормышның матди дәрәҗәсе турында бик аз нәрсә сөйли. Бердән, бәяләрнең уртача күрсәткечен чыгару – бик мөшкел эш. Мәсәлән, авылдагы ике кибеттә бәяләр ике төрле, кайбер товарларның бәясе хәтта ике тапкыр диярлек аерыла. Әйтик, син товарны кыйммәтле кибеттән алгансың икән, уртача бәя синең кесә хәленә аз гына да җиңеләйтми. Эш шуның белән катлаулана: кайсы кибеттә кайсы товарның ни бәядә торуын белү артык зур мәшәкать сорый. Ике кибет арасында чабып, бәяләр чагыштырып йөреп булмый бит инде. Шуңа күрә «берәү алдый, берәү алдана» дигән Тукай формуласы – базар өчен котылгысыз нәрсә.

Хәзерге азык-төлек бәяләре арасында инфляция давылларына бер дә исе китми торган бер продукт бар: ул – бал. Моннан бик күп еллар элек тә балның бер банкасы (якынча дүрт килограмм) меңнән биш йөз сум йөри иде. Хәзер дә шулай. Әмма күпкә арзангарак та табып була. Соңгы көннәрдә генә бу юлларның авторы банкасын мең сумнан гына 3 банка бал алды. Килосы 250 сум дигән сүз бит инде бу. Күләм чикләнмәгән, бер тонна алырга була, сыйфат телтеш тидерерлек түгел. Чагыштырыгыз: Татарстанда шикәрнең хәзерге көндәге уртача бәясе – 63 сум 06 тиен. Иң кыйммәтле шикәр Алексеевск районында – 71 сум 69 тиен. Зәй районында иң арзанлы шикәр – 57 сум 08 тиен. Шикәрнең уртача бәясен ничек чыгарасың һәм ул уртача бәядән алексеевскилыларга ни файда бар? 2022 ел гыйнварында, махсус хәрби операция безнең әле төшкә дә кермәгәндә, Татарстанда шикәрнең уртача бәясе 55–57 сум торган. Ул чакта Тәтеш районында шикәрне 53–54 сумга гына сатканнар.

Бал турында яза идем бит әле. Бал бәясе, махсус хәрби операциягә дә, шикәр бәяләренә дә, инвесторларның пестицидлар белән кортларны бердәм рәвештә агулап үтереп бетерүләренә дә карамастан, тотрыклы кала. Бу феноменны өйрәнеп нәтиҗә ясарга теләүче берәр икътисадчы, маркетолог булырмы икән? Әйтик, өйрәнәсең дә базар өчен уртак бер формула чыгарасың. Шул формуланы сәнәгать товарларына кулланасың, аннан авыл хуҗалыгы өлкәсенә дә кертәсең. Киресенчә эшләргә ярамый, чөнки авыл болай да бал формуласы белән эшли: алтыга ала, бишкә сата. Монда бер нәрсәне искәртергә кирәк: авторның сәнәгать товарларына карашы чиновникларныкына һәм икътисадчыларныкына караганда төптән аерыла. Әйтеп карагыз әле: ипи – авыл хуҗалыгы товарымы, сәнәгатьнекеме? Берсүзсез сәнәгатьнеке. Авылныкы булса, аның бәясе ашлык бәясе төшү белән түбәнгә китәр иде. Яңа Россия тарихында кайчан да булса ипигә бәя төшкәнне ишеткәнегез-күргәнегез бармы сезнең? Ак сакалыны тотып әйтәм, минем – юк. Сөт тә – шулай ук сәнәгать товары. Авылныкы булган өлешенә бәя бик түбән аның, җәйгә таба төшә дә. Чиновниклар аны үзкыйммәте җәен түбән була дип аңлатмакчы булалар. Ләкин алар бер нәрсәгә җавап бирмиләр: ни өчен кибеттә сөт җәен арзанаймый соң? Быел бездә сөтнең сатып алу бәясе кышка таба арзанайды. Үзкыйммәт түбәнәйдемени? Әйе, әйе, дөрес әйтәсез, ашлыкка бәя төште, әмма печәнгә күтәрелде. Әмма икътисадның сәнәгать дигән тармагында бәя үзкыйммәт белән йөрми ул. Базарда андый төшенчә юк: анда ихтыяҗ һәм тәкъдим итү дигән нәрсә бар, бәяне шул билгели. Хакимиятнең икътисад һәм планлаштыру өчен җаваплы чиновниклары, минем уйлавымча, менә шул ике нәрсәне баланслаштыру белән шөгыльләнергә тиеш. Әйтик, инвесторлар табарга, сәүдә нокталарын арттырырга, көндәшлекне тәэмин итәргә.

Ипи дигән сәнәгать товары мисалында Татарстан районнарында хәл ничек тора, шуны карыйбыз, әйдә. Чагыштыру өчен кара ипи – арыш-бодай оныннан пешерелгән икмәк бәясен алабыз. Бер килограмм кара ипи бәясе Чистайда – 74 сум 82 тиен. Шушы урында туктап әйтеп үтим әле: ипи бәясе турында язгач, газета хәбәрчесенә чиновниклар шалтырата кайчак: «Каян алдың ул бәяләрне?» – дип әйтәселәре килә. Хөрмәтлеләрем, Татарстанда атна саен базар бәяләрен мониторинглап баручы хезмәт бар һәм аның таблицалары һәр район хакимиятенең социаль мәсьәләләр өчен җаваплы хезмәткәрләренең өстәлендә ятарга тиеш, дип фикер йөртәм мин үзем. Шулай булмаса, сез социаль мәсьәләләрне ничек хәл итәсез соң инде? Сүз ипи бәясе турында бит әле. Әгерҗе районында кара ипи бәясе килосына 51 сум гына. Мәгълүматлар быелның 1 мартыныкы. Мөслим, Алабуга, Азнакай, Бөгелмә, Алексеевск, Минзәлә, Әгерҗе районнарында ипи арзан йөри, Казанда, Түбән Кама, Әлмәт, Чирмешән, Чистай, Буа районнарында кыйммәт һәм бәяләр бик кискен аерыла. Ипи – социаль әһәмиятле продукт, кара ипине аз керемле пенсионерлар ала. Аларның пенсиясе бар районнарда да бертөрле. Бик җитди мәсьәлә бит, уйлап карасаң. Әйе, әйе, районнар арасында он бәясе дә бик нык аерыла. Теләчедә бер килограмм югары сортлы бодай оны – 57 сум 09 тиен, Апаста – 38 сум 13 тиен. Әмма Апаста ак ипи иң арзанлысы түгел. Димәк, ипи бәясен билгеләүдә он бәясе беренчелекне тотмый. Ак ипи дигәннән, аның да иң кыйммәтлесе Казанда һәм Биектау районында. Килосы Казанда – 109 сум 03 тиен. Бу Апастагы ак ипи бәясеннән 1,74 тапкыр кыйммәт. Апас оны белән Казан оны арасында бәя аермасы алай ук зур түгел. Бер килога 15 сумга да тормый. Казанда бер кило ак он 52 сум 74 тиен тора. Автор үз куллары белән эшләп карап белә: бер кило оннан өч кибет ипие пешереп була. Рәсми рәвештә бер кило оннан бер кило 400 грамм ипи пешерелә дип санала. Практикада ипи аннан да авыррак килеп чыга. Әйтеп карагыз инде, ипи бәясе үзкыйммәткә бәйле, дип. Бу очракта салымнар белән дә аңлатып булмый, чөнки бар җирдә дә салымнар бердәй.

tatarstan.ru

Үткән ел ашлык кыйммәтрәк иде, әмма он быелгыдан арзанрак йөргән. Икмәк тә арзанрак булган әле. Бәяләр үсәргә бернинди дә сәбәп күренми шикелле. Әйе, чыгымнар арта инде ул. Энергия чыганаклары кыйммәтләнә. Хезмәт хакларын да үстерми булмый. Моннан бик күп еллар элек бер популяр газетаның штаттан тыш популяр авторы: «Бәяне ник күтәрәсез?» – дип, энергетикларга шалтыратуын язган иде. Алар нәрсә дип җавап биргәннәр дип уйлыйсыз? «Ипи бәясен карагыз, ипи бәясе күтәрелгәндә, без ач утырыйкмы?» – дигәннәр. Шуннан автор ипи бәясен чагыштырып караган да шаккаткан: аның бәясе паровоздан алда чаба икән.

Бездә икътисадчыларның бик зур армиясе эшли. Бюджеттан финансланучы икътисад мәктәпләре дә җитәрлек, мәгълүмат базарында үз көчләре белән акча табучылар да буа буарлык. Тик алар никтер я уртача инфляция исәпләү белән генә шөгыльләнәләр, я финанс спекуляцияләре ясарга өйрәнү һәм өйрәтү белән мавыгалар. Ә реаль икътисадның табышка да эшли торган, бәяләрне дә йөгәнли торган моделен булдыру турында уйлаучылар юк. Югыйсә бер-берсеннән кул сузымы гына ераклыкта булган районнар арасында икмәк бәясенең дистәләгән процентлы аермасыннан котылу өчен әллә ни күп тә кирәкми шикелле. Бәяләр иң түбән булган районнардагы шартларны тудырасың, бары шул гына.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ПУМАЛА ТОТЫП КУЛГА

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кемгә – буяу, кемгә – җилем

«ВсеИнструменты.ру» порталы уздырган сораштыруда катнашучыларның 34 проценты быел йортында ремонт ясарга җыенуын әйткән. Аларның 75 проценты якын арада – фатирын, 17 проценты – шәхси йортын, тагын 8 проценты бакчасын төзекләндерергә тели. Респондентларның яртысыннан артыгы ремонт өчен якынча 200–300 мең сум акча сарыф итәргә җыена.

Саннар да шул хакта сөйли. Росстат мәгълүматларына караганда, быел гыйнварда Россиядә төзелеш материалларына ихтыяҗ ике тапкыр, эчке төзелеш материалларына дүрт тапкыр арткан. Башкаладагы төзелеш материаллары кибетендә сатучы-консультант булып эшләүче Рөстәм Гатауллин сүзләренчә, Яңа елдан соң халык, дөрестән дә, мондый кибетләргә тузан кундырмый икән.

– Халык артык акчасын ремонтка туздыру ягын карый. Хәзер бит аңа машина да, фатир да алырлык түгел. Иң отышлысы шул. Буяу, монтаж күбеге, плитка, герметик, линолеум, плинтуслар аеруча күп сатыла, – ди ул.

Казанда фатирлар төзекләндерү белән шөгыльләнүче бригада җитәкчесе Рәсим Вәлиев тә быел эшсез тормаячакбыз дип сөенә.

– Яңа ел яллары вакытында да шалтыратучылар бик күп булды. Заказлар уртача 30 процентка артты дип әйтә алам. Узган ел кешедә ремонт, төзелеш кайгысы булмады бит. Аннары әлегә материал бәяләре дә чагыштырмача тотрыклы саклана. Аларга сорау да шул сәбәпле арткандыр, – ди ул.

pixabay.com

Тимер, агач чират көтә

Ремонт өчен кирәк-яраклардан аермалы буларак, бүген төзелеш материалларына ихтыяҗ мактанырлык түгел. Күреп торабыз: соңгы бер ел төзелеш материаллары базары өчен дә катлаулы чор булды. Мәгълүм вакыйгалардан соң илдә төзелеш материаллары хакы икеләтә, кайберләренә өчләтә артты. Җитештерүчеләр моны Россиягә каршы кертелгән санкцияләргә бәйләп аңлатты. Төзелеш материаллары коточкыч дәрәҗәдә кыйммәтләнү белән аларга булган сорау да кисәк кимеде.

Узган елның июль – август айларына исә төзелеш материаллары бәясе элеккеге дәрәҗәсенә кайтты (таблицада. – **Д.Г.**). Бу хәбәрне җиткергәндә, Татарстан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин, төзелеш материалларына кытлык булмаячак, дип тә вәгъдә итте.

– Тимергә бәя 24 февральгә кадәр үк бик нык артты. Ул хәтта 70–80 процентка кадәр күтәрелде. Бу исә барлык төзелеш материалларының бәяләре артуга китерде. Хәзерге вакытта без аларның хаклары бераз төшүен күрәбез, бәяләр нормальләште. Европадан кертелә торган төзелеш материаллары базары Белоруссия һәм Төркиягә күчте. Төзелештә кулланыла торган күп эшләнмәләр Россия заводларында җитештерелә башлады. Әгәр йорт салырга уйлыйсыз икән, анда кулланыла торган материалларның 85 проценты үз илебезнеке булачак. Шуңа күрә йорт төзүгә комачаулык итә торган проблемалар күрмибез, – дип белдергән иде министр узган җәй журналистлар белән очрашуда.

Арча районындагы эре металл ширкәте җитәкчесе Фәнис Гарәфиев әйтүенчә, узган елның җәй уртасына төшкән хаклар бүген дә шул дәрәҗәдә саклана бирә. Мисал өчен, бер тонна арматура бәясе, 17,5 мең сумга арзанаеп, бүген 50,8 мең сум тәшкил итә. Табаклы металлның бер тоннасы 109 мең сумнан 82 мең сумга кадәр төшкән.

– Бүген бездә тимергә дә, сэндвич-панельләргә дә ихтыяҗ зур түгел. Узган елдан бирле шундый хәл күзәтелә. Алга таба нәрсә буласын вакыт күрсәтер. Шулай да, көтелмәгән хәлләр килеп чыкмаса, металл бәяләре акрынлап үсәр ул, – дип фаразлый Фәнис Гарәфиев.

ТӨЗЕЛЕШ МАТЕРИАЛЛАРЫ ХАКЛАРЫ НИЧЕК ҮЗГӘРГӘН?

(Татарстан Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәгълүматлары буенча)

	Узган елның I кварталында уртача бәя (мең сумнарда)	Узган елның II кварталында уртача бәя (мең сумнарда)	Күпмегә үзгәргән (процентларда)
такта, 1 м³	21,2	19,2	–9
керамик кирпеч, 1000 данә	19,4	24	+24
силикат кирпеч, 1000 данә	11	14,5	+32
бетон, 1 м³	4,5	4,9	+10
цемент	2,7	2,9	+9
елга комы, 1 т	0,326	0,312	–4
вак таш, 1 т	2,3	2,6	+10

Агачка да сорау зур түгел. Башкаладагы агач материаллары җитештерүче ширкәт вәкиле Ольга Логинова сүзләренә караганда, агач материалларына ихтыяҗ да, аның бәясе дә ике ел рәттән кими бара. «Бездә әле мондый ук торгынлыкның булганы юк иде. Әйтик, әле кайчан гына тактаның бер кубометры 21,1 мең сум тора иде. Хәзер ул 18 мең сумга калды. Алучы булмаса, агач бәяләре алга таба да кимеячәк», – ди Ольга.

Агына кытлык

Агач белән тимердән аермалы буларак, соңгы арада кирпеч алырга теләүчеләр арта башлаган. Һәрхәлдә, Россиядәге күп кенә эре кирпеч заводларының Татарстандагы дилеры булган оешма җитәкчесе Наталья Кукушкина шулай ди.

Моннан ике ел чамасы элек бер сөйләшүебездә кирпечкә ихтыяҗның коточкыч дәрәҗәдә зур булуын, күпләргә, кирпечкә заказ биргәч, 2–3 ай көтәргә туры килүен шаккатып сөйләгән иде ул. Шул чорда хәтта заводта бер-ике айдан чыгачак яңа партия кирпечләр өчен дә алдан акча түләп куючылар булган. Хәзер ул вакытларны сагынып сөйләргә генә калган.

– Узган елның февраль, март айларында кирпеч күпләп сатылды әле. Аннары безнең өчен авыр чор башланды. Бу аңлашыла да, күпләр төзелешкә дип җыйган акчасын «кара көн»гә калдырды. Төзү, төзекләндерү эшләре кайгысы калмады. Быелның февраль уртасыннан кирпечкә ихтыяҗ арта башлады. Чөнки кеше, акрынлап шоктан айнып, гадәти тормышка кайта башлады. Бу пандемия чорында да шулай булды, – ди белгеч.

Сорау бәягә дә йогынты ясый, билгеле. Наталья Кукушкина сүзләренә караганда, бер ел эчендә кирпечнең кайбер төрләре 30–40 процентка арзанайган. Әйтик, моңа кадәр 30 сум чамасы торган икеле керамик кирпеч бүген 20 сум тора. Элегрәк 18 сум торган гади кирпечне бүген 12–13 сумга табарга мөмкин. Дөрес, белгеч фикеренчә, мондый бәяләр – вакытлы күренеш. Кирпечкә сорау арта башлагач, хаклар да тиз арада үсәчәк, дип фаразлый ул.

Россиягә каршы кертелгән чикләүләр кирпеч җитештерү тармагына нинди үзгәрешләр керткән? Эре оешма җитәкчесеннән шул хакта да сораштык.

– Чикләүләр кертелгәч, кайбер заводларга җитештерелә торган продукция, чимал төрләрен үзгәртергә, башка чимал китерүчеләр белән эшләргә туры килде. Санкцияләр бигрәк тә ак кирпеч җитештерүгә йогынты ясады. Ник дигәндә, аны җитештергәндә, Украина балчыгы кулланыла иде. Шуңа күп кенә заводлар бик кыен хәлдә калды. Хәзер ачык төстәге керамик кирпечкә кытлык күзәтелә. Бүген ак кирпеч күпләп Белгородта җитештерелә. Әмма аны кайтарту бәясе дә, юл чыгымнары да кыйммәткә төшә, – ди Наталья Кукушкина.

Ремонтныкы артачак

Төзелеш материаллары базарын алга таба ни көтә? Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов сүзләренә караганда, соңгы арада төзелеш һәм ремонт өчен кирәкле материалларга сорау арту, иң беренче чиратта, аларга бәяләрнең тотрыклануына бәйле. Бу күренешкә Россиягә яңа кушылган төбәкләрдә төзелеш эше алып бару да йогынты ясый, дип саный белгеч.

– Төзелеш материаллары хаклары киләчәктә дә артык үсәр дип уйламыйм. Алар инфляциягә бәйле рәвештә үсәчәк. Тимер җитештерүчеләр, санкцияләргә бәйле рәвештә эчке сорауны арттыру ниятеннән, хакларны берникадәр төшерергә дә мөмкиннәр. Узган ел сорау аеруча зур булган М200 маркалы бетон бәяләре болай да 3 меңнән 4,1 мең сумга кадәр арткан иде. Алар киләчәктә дә мондый темплар белән артыр дип уйламыйм. Ник дигәндә, бездәге төзелеш материаллары җитештерүчеләр технологияләрен саклап кала алдылар. Аларның күбесен җитештерү өчен кирәкле чималлар үзебездә дә бар. Безнең агач кисү, агач эшкәртү сәнәгате, чикләүләр аркасында, хәзер үз продукцияләрен эчке базарга юнәлтә. Шуңа күрә алар бәяләрне арттырмаслар, бәлки, төшерү җаен да табарлар, – ди белгеч.

Ә менә ремонт ясар өчен кирәкле эчке төзелеш материаллары, киресенчә, кыйммәтләнәчәк, дип фаразлый ул. Чөнки аларны җитештергәндә, чит ил җиһазлары кулланыла. Мисал өчен, хәзер төрле изоляция материаллары җитештергәндә кулланылган җиһазларның 70 процентын чит илнекеләр тәшкил итә. Төзелеш химиясендәге җиһазларның да 90 проценты – чит илнеке.

– Шуңа күрә якын арада сантехника, керамика, герметикларга да бәя артырга мөмкин. Обой, фурнитура, буяу кебек кирәк-яракларның да кыйммәтләнүе ихтимал, – ди Илгизәр Гайнетдинов. – Төзелеш материаллары бәясен төшерергә теләсәк, хөкүмәт логистика чыгымнарын субсидияләргә тиеш. Бер генә мисал: санкцияләргә кадәр тимер юл аша төзелеш материалы кайтаруның бер чакрымы 2300 сум йөри иде. Чикләүләрдән соң ул, өч тапкыр артып, 7900 сумга җитте, – ди ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Эльвира ВӘЛИЕВА

ЙӨККӘ КЕРГӘНЧЕ... ЮККА

Бурычлы үлмәс, бурычсыз көн күрмәс. Әлеге мәкальнең сүзләрен үзгәртергә туры килмәгәе. Белгечләр әйтүенчә, ил халкының акча тотуга мөнәсәбәте үзгәргән. Былтыр банкта кредит рәсмиләштерүчеләр саны өчтән бер өлешкә диярлек кимегән әнә. Бурычка да алмыйлар, үзләре дә бирмиләр. Сораштырудан күренгәнчә, россиялеләрнең яртысы диярлек әҗәткә акча бирми башлаган. Хәтта туган-тумачага да. Без әле кая барабыз? Әлеге сорауга җавапны «ВТ» хәбәрчесе дә эзләде.

Кредитсыз да тормыш бар

Казанда яшәүче Илнар Газизуллин узган ел азагында гына биш ел буе түләгән куллану кредитын япкан. Моннан ары банкларга борылып та карамыйм, ди ул.

– Шәһәр янындагы бистәдә йорт салганда кирәк-яракка дип банктан 700 мең сум кредит алган идек. Бик тынгысыз бакыйла элэктек. 6,5 процент белән бирелгән кредитны ахыр чиктә 14 процент белән түләп бетердек. Алганның ярты бәясен өстәп түләдем. Юрганыңа карап, аяк сузарга кирәк икән. Бүген беркемгә дә ышаныч юк. Шуңа күрә моннан ары бурычка яшәмәячәкмен, – ди гаилә башлыгы.

Былтыр илдә яшәүчеләр 12,5 миллион тапкыр куллану кредиты алган. Илкүләм кредит тарихлары бюросы мәгълүматлары шул хакта сөйли. Алдагы ел белән чагыштырганда, банкка мөрәҗәгать итүчеләр саны 27 процентка кимегән, ди белгечләр. Алдан ук шунысын искәртик: сүз көнкүреш һәм шәхси кирәк-яраклар өчен алынган акча турында бара. Куллану кредитын былтыр күбрәк Мәскәү (715 мең тапкыр), Мәскәү өлкәсе (608 мең тапкыр) һәм Краснодар краенда (476 мең тапкыр) рәсмиләштергәннәр. Беренче бишлеккә Башкортстан һәм Санкт-Петербург та эләккән. Татарстан – алтынчы урында. Узган ел республикада яшәүчеләр 416 мең тапкыр куллану кредиты рәсмиләштергән.

Аның каравы без – көнкүреш кирәк-яракларына дип әҗәткә акча алучылар иң күп кимегән төбәкләр арасында. Банкларны читләтеп узучылар Самарада күбрәк. Биредә куллану кредитын рәсмиләштерүчеләр саны бер елда 28,4 процентка азрак теркәлгән. Беренче өчлектә Ставрополь крае (–28,2%) һәм Волгоград өлкәсе (–27,9%) дә бар. Татарстанда исә бурычка керүчеләр 27,2 процентка кимегән. Узган елның гыйнвар – сентябрь айларында республика халкы 62 миллиард сумлык куллану кредиты алган. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 40 процентка азрак.

Башкаладагы банкларның берсендә кредит белгече булып эшләүче Алисә Вафина әйтүенчә, халык кредит рәсмиләштерүгә саграк карый башлаган.

– Бурычка акча алу тәртибен сорап, кат-кат мөрәҗәгать итүчеләр дә бар. Болай эшләсәң, ничегрәк икән, дип киләләр дә, уйларга кирәк, дип кире борылып чыгып китәләр. Аларны да аңлап була. Куллану кредиты ставкасы, килешү төзегәндә тәкъдим ителә торган имминият хезмәтләрен дә кертеп, 20 процентка кадәр җитә. Коронавируслы 2021 елда да ул 12–14 проценттан артмады. Иртәгәге көнгә ышаныч булмагач, сабыр итүне кулайрак күрәләр, – ди белгеч.

Җиде кат үлчәп аласы

Икътисад белгече Илдус Сафиуллин сүзләренә караганда, икътисадый тотрыксызлык һәм мәгълүм вакыйгалар аркасында, халык акчаны артык әрәмшәрәм итмәскә тырыша.

– Илдә үткәрелгән тикшерүләр дә шуны раслый. Махсус хәрби операция башланганнан бирле илдә кием-салым кибетләренә, кафе-рестораннарга йөрү, өйгә әзер ризык заказ бирү, такси һәм клининг хезмәтләреннән файдалану кебек өстәмә чыгымнардан баш тартучылар саны 58 процентка җиткән. Димәк, халык акчаны янга калдырырга тырыша. Акча янчыгына мөнәсәбәтне үзгәртергә мәҗбүр иткән тагын бер мөһим факт – илдә яшәүчеләрнең матди хәле начараю. Бәяләр артканнан-арта, ә хезмәт хаклары әллә ни үзгәрми диярлек, – ди белгеч.

Кесә ягы саегуны халыкның банкларга җыелган бурычы да дәлилли. Бөтен төр кредитларны исәпкә алып, ил халкының финанс оешмаларга 27 триллион сум (!) әҗәте бар, ди белгечләр. Бу – рекорд. Бурычлыларның яртысы диярлек – ипотека йөген тартып баручылар.

Банкротлык үзәге юристы Дмитрий Кочергин фикеренчә, әҗәтлеләрнең күбесе – томшыгын алса, койрыгыябышкан, койрыгын алса, томшыгыябышкан саескан кебек, бер бурычны ябарга дип икенчесен алучылар.

– Кая карама: урамдагы игълан такталарында да, телевизордан да гел «акча алыгыз» дип кенә торалар бит. Кредит рәсмиләштерүне бик җиңел эш итеп күрсәтергә тырышалар. Моның өчен документ та кирәкми, вакыт та бик аз таләп ителә, имеш. Нәтиҗәдә бер кеше биш кредит ала да бурычын түли алмас дәрәҗәгә җитә. Бурыч тозагына батучыларның күбесе – берсен түлим дип, икенчесен, алар өстенә өченчесен алучылар. Алар бу эшнең азагын уйламый. Узган елның беренче яртысында илдә яшәүче 120 меңнән артык кеше банкрот дип танылды, – ди юрист.

Ул арада банклар кредит рәсмиләштерергә теләүчеләрне илектән үткәрә башлаган инде. Илкүләм кредит тарихлары бюросы мәгълүматларына караганда, былтыр илнең финанс оешмалары бурычка акча алырга килгән һәр дүртенче кешегә генә уңай җавап биргән. Тәгаен әйтсәк, барлык гаризаларның 26 процентын хуплаганнар. Бер ел элек кенә әлеге күрсәткеч 33 процент тәшкил иткән.

Киләчәктә мошенниклар да чит кеше исеменә кредит рәсмиләштерә алмас, дип фаразлана. Россия Дәүләт Думасына әнә шундый эчтәлектәге закон проекты тәкъдим итмәкчеләр. Кырыгалдарлардан саклану өчен, Дәүләт хезмәтләре порталында махсус «тыю» төймәсе барлыкка киләчәк, ди. Бурычсыздан бурычлы булып калырга теләмисең икән, махсус кушымтага рәхим ит.

Мә, туганым, 16 мең

«SuperJob порталы үткәргән сораштырудан күренгәнчә, россиялеләрнең 23 проценты, бик кирәк булса, банктан бурычка акча алырга әзер. Ә менә респондентларның 55 проценты әҗәтле булып яшәргә теләми. Былтыр болай фикер йөртүчеләр 50 процентка да тулмаган. Бурычка акча алмау белән беррәттән, ил халкы әҗәткә акча бирергә дә ашкынып тормый. Респондентларның 44 проценты: «Бурычка акча бирмим», – дигән. Чагыштыру өчен: бер ел элек болай дип кырт кисүчеләр 30 процент тирәсе тәшкил иткән. Узган ел туганнарына һәм дусларына әҗәткә акча биреп торырга әзер булганнар саны да сизелерлек кимегән. Респондентлар моны тормыштагы тотрыксызлык белән бәйләп аңлаткан. «Кул белән биргәнне аяк белән алырга туры килә», – дип фикер йөртүчеләр дә шактый. Барыннан да бигрәк, эштәге хезмәттәшләргә ышанмыйлар икән. Сораштыруда катнашучыларның 30 проценты хезмәттәше алган бурычны бик озак көтәргә туры килүен әйткән. Әҗәткә бирергә мөмкин булган акчаның уртача күләме дә билгеле. Илдә яшәүчеләр туганнарына – уртача 16 мең, дусларына 11 мең 500 сум акча биреп торырга әзер.

Психолог Венера Касыймова да бурычка акча бирмәвең хәерлерәк дип саный.

– Бу – һәркемнең үз эше, әлбәттә. Тик хәләл көч белән эшләп тапкан акчаның кадерен белүчеләр мондый юлга барырга тиеш түгел. Әҗәткә акча әләшү ул начар гадәт кебек. Кыен хәлдә калган туганнарга, дусларга ярдәм итү теләге – бер нәрсә. Ә менә кеше алдында яхшатлы булып калу өчен генә бурычка акча бирүнең ике якка да файдасы юк. Сез әҗәт сораган кешегә, киресенчә, зыян гына саласыз. Бирүчеләре булганда, бурычка яшәргә күнеккән кеше алга таба да кул сузып йөреячәк. Бәлки, аңа акча эшләргә, мәсәлән, эшкә урнашырга ярдәм итәргә кирәктер. Үзең эшләп тапкан акча гына кадерле.

Фикер

Тимур хәзрәт КАМАЕВ, «Ирек» мәчете имам-хатыйбы:

– Коръәннең «Бәкара» сүрәсендә әҗәткә акча алу турында бер битлек аять бар. Башка андый озын аять юк. Ул безгә, әҗәткә алганда-биргәндә шаһитлар булсын, ди. Ике шаһит кирәк. Биредә расписка мәсьәләсе дә күтәрелә. Дуслар булса да, мөселманнар булса да, кешенең нәфес дигән әйбере беркая да китми. Мөселманнарга карата Аллаһы Тәгалә әйтә: «Бурычка акча алганда ике шаһит булсын», – ди. Югыйсә бизнесменнар еш кына, син мөселман, мин мөселман дип, сүздә генә үзара килешеп эшкә керешәләр дә аннары мал бүлешә башлыйлар. Талашып, казыйга кадәр барып җитәләр. Андый хәлләр булмасын өчен, Аллаһы Тәгалә безгә чарасын биргән. Бурычка биреп тору ул – үзе бер савап. Син бит мөселман кардәшеңә ярдәм итәсең. Кемгә булышырга теләгәнеңне дә белергә кирәк. Мәсәлән, акча хәмергә тотылырга тиеш түгел. Мөселманның хәле авыр булуын күрәсең икән, әҗәтне гафу итү сөннәте дә бар. Имам Әгъзам Әбү Хәнифәнең дә тормышыннан китерелә бу мисал. Берәү аннан әҗәткә акча ала да, кайтарырга акчасы булмый. Оялып, күзенә күренмәскә тырышып йөри башлый. Әбү Хәнифә моны аңлап ала да, аны куып җитеп: «Мин синең әҗәтеңне гафу итәм», – ди. Бу саваплы эшләрдән санала. Кешене сәдакага өйрәтергә дә ярамый. Пәйгамбәребез (с.г.с.) тормышында берәү бурычка акча сорап килгәч, ул аңа акча биреп, балта сатып алдырта һәм утын ярдырып, һөнәргә өйрәтә.



БУРЫЧКА АКЧА КЕМНӘН АЛАСЫЗ?

- Бурычка акча алмыйм.............55%
- Банктан.................................23%
- Туганнардан...........................11%
- Дуслардан.............................7%
- Эштәге хуҗадан......................1%
- Хезмәттәшләремнән...............2%
- Башка җавап..........................1%



БУРЫЧКА АКЧА КЕМГӘ БИРӘСЕЗ?

- Бурычка акча бирмим..............44%
- Туганнарга..............................22%
- Дусларга.................................21%
- Хезмәттәшләремә...................8%
- Башка җавап...........................5%

Зөһрә
САДЫЙКОВА

ӨЗЕП БИРЕР КЕШЕҢ БУЛСЫН

Һавада – баш әйләндергеч чәчәк исе. Язның беренче бәйрәмен билгеләп узарга бер атна чамасы вакыт булса да, базарлар, кибетләр аллы-гөлле лалә, башка төрле купшы чәчәк бәйләмнәренә чумды инде. Алар каян кертелә һәм чәчәк базарында нинди вазгыять хөкем сөрә? Бәйрәм алдыннан иң романтик бизнес вәкилләре белән аралаштык.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Матурлык туганда

Балтач районының Смәел авылындагы теплицасында бүлмә гөлләре, чәчәк үсентеләре үстерүче Илнур Латыйпов быел беренче тапкыр лалә чәчәкләре утырткан. Чөнки ихтыяҗ зур. Эшмәкәр чәчәк бизнесы белән 2012 елдан бирле шөгыльләнә. Аңа кадәр 15 сутый җирдә суган, кыяр үстергән. Хәзерге вакытта 1200 квадрат метр мәйданда иртә яздан башлап көзгә кадәр күзләрне аллы-гөлле матурлык иркәли.

– Эшемне бакча чәчәкләреннән башлаган идем. Сораучылар күп булгач, быел беренче тапкыр лаләләр утыртып карарга булдык. Мин аны яңа технология буенча, туфракта түгел, ә суда (гидропоник ысул) үстердем. Мине һәрвакыт каяндыр алып сату түгел, ә үзем җитештереп карау кызыктырды. Чәчәк бизнесында да кереминнән бигрәк, сыйфатлы, яңа продукт җитештерү процессы ошый, – ди ул.

Теләсә нинди бизнестагы кебек, авырлыклар монда да бар, билгеле. Узган ел санкцияләр кертелгәч, Европадан ала торган үсентеләргә бәяләр бик нык арткан. Үсенте, орлыкның гына түгел, барлык кирәк-яракларның бәясе 30–40 процентка кадәр күтәрелгән.

– Чәчәкнең үзкыйммәте артса да, сату бәяләрен ул дәрәҗәдә күтәреп булмый. Шуңа күрә үзгәреш җилләре чәчәк бизнесындагы керемнәрне шактый какшатты. Үземнең дә әлегә үстерү мәйданнарын арттыру уе юк. Эшебез бик күп, ел дәвамында туктап торганыбыз юк. Дөресен әйткәндә, утырып анализларга да вакыт җиткереп булмый. Моңа кадәр лалә, бүлмә гөлләре белән мәш килсәк, хәзер менә бакчада үсә торган чәчәкләргә тотынабыз. Гүзәл затларыбызга бәйрәм кәефе бүләк итәр өчен, без инде сентябрьдән үк тырыша башлыйбыз, – ди Илнур.

Ә бәйрәм кәефе инде бүгеннән сизелә.

– 8 Март бәйрәменә билгеле бер төр чәчәкне генә яратып алалар, дип әйтә алмыйм. Барлык чәчәкләргә дә өстенлек бирәләр, – ди матурлык тудыручы эшмәкәр. – Бу көннәрдә лалә белән бергә чәчәк аткан бүлмә гөлләре дә яхшы сатыла. Сатып алучылар арасында ниндидер ыгы-зыгы юк. Барысы да елдагыча тәртип белән бара, башка вакытка караганда, бәлки, активлык бераз гына арта торгандыр.

Үзеңнеке – үзәктәме?

Чәчәк кибетләре тотучы Гүзәлия һәм Фаил Динмөхәммәтовлар чәчәк бизнесына 2016 елда керешә. Кибетләрен алар башта Арчада, аннан соң Кенәр авылында, күптән түгел генә Биектауда ачканнар.

– Мин – икътисадчы. Үз профессиям буенча эшләп карадым, тик күңелем аралашуга һәм матурлыкка тартылды. Кечкенә балам белән өйдә утырганда, ирем чәчәк кибете ачарга тәкъдим итте. Аларны бик яратсам да, башта куркытты, әлбәттә. Тик теләк куркудан өстенрәк булып чыкты. Беренчедән, мин аралашырга яратам, икенчедән, иҗади кешемен. Әлеге һөнәремдә шушыларның барысын да файдаланам, – ди флорист ханым. – Читтән караганда бик төшемле бизнес кебек күренсә дә, һәр эшнең үз авырлыгы бар. Ләкин кайда нәрсә генә эшләсәң дә, хезмәтеңне яратып башкарырга кирәк. Бары тик шул очракта гына уңышка ирешеп була.

Гүзәлия ханым әйтүенчә, соңгы вакытта бәйрәмнәр алдыннан халык арасында ыгы-зыгы юк. Аларның кәефенә, беренчедән, мәгълүм вакыйгалар йогынты ясаса, икенчедән, бәяләр арту да үзен сиздерә.

– Чәчәк бәяләре арткач, сатып алулар кимеде. Ул быел бигрәк тә нык сизелә. Дөресрәге, клиентлар шулай ук калды, алар якыннарын сөендерер өчен ничек тә мөмкинлек табалар. Ә менә купшылык кимеде. Әйтик, элек биш роза чәчәге сатып алучылар хәзер өч белән генә чикләнә. Шуңа күрә хәзер чәчәкләрне азрак кайтартабыз, – ди ул.

Кибетләрендә Эквадор, Голландия, Колумбия, Италия чәчәкләре сатыла. Россия төбәкләре, Татарстан җитештерүчеләренеке дә бар.

– Соңгы берничә елда Россиядә чәчәк үстерүче эре эшмәкәрләр саны артса да, әлегә бизнес өчен кирәкле барлык товарлы да җитештермиләр. Тагын шунысы бар: чит ил чәчәкләре сыйфатлары буенча яхшырак, ә менә бүлмә гөлләренең үзебездә үскәннәре әйбәт. Чөнки, урау юллар узганлыктан, чит илдән кайта торган гөлләр сыйфатын югалта башлады. Шуңа күрә миңа хәзер чит ил чәчәкләрен кайтаручылар белән дә, Россия җитештерүчеләре белән дә эшләргә туры килә. Лаләнең, мәсәлән, Россия һәм Татарстанда үскәннәрен сатабыз, чөнки алай арзангарак чыга, – ди Гүзәлия Динмөхәммәтова.

Шулай да, эшмәкәр ханым әйтүенчә, авырлыкларга карамастан, чәчәк бизнесы торгынлык кичерми. Соңгы арада Арчада гына да берничә чәчәк кибете ачылуын әйтте.

8 Мартка халык шау чәчәктә утыручы гөлләрне яратып алса, чәчәкләр арасында лаләгә тиңнәр юк. Быел бер данәсен 80–100 сумнан саталар. Яшьләр тыныч тоннарга өстенлек бирсә, өлкәннәр янып торган, ачык төсләрне сайлый икән.

– Соңгы елларда ир-атларның хатын-кызларга хөрмәте, игътибары арту сизелә, – ди ул. – Аралашканда ир-атның хатынына, әнисенә яки кыз туганына, хезмәттәшенә булган мөнәсәбәтен дә тоемлыйбыз. Элек Әниләр бәйрәменә гөлләмәләрне әниләренә генә алсалар, хәзер гаилә башлыклары хатыннарын да сөендерергә тырыша. Мондый караш безне, чәчәк сатучыларны, бик куандыра, әлбәттә.

Лалә үзебезгә җитә

Илкүләм чәчәк үстерүчеләр ассоциациясе идарәсе рәисе Алексей Антипов сүзләренә караганда, быел чит илдән кертелгән лалә чәчәкләре бик аз һәм алар кыйммәт булачак. Хәер, мондый вазгыять Россия базарында 5-7 ел күзәтелә инде, ди ул.

– Сәбәбе санкцияләргә дә, коронавируска да, башка вагыйгаларга да бәйле түгел. Чәчәкчелек тармагында импортны алмаштыру нәтиҗәсе бу, – дигән Алексей Антипов. – Россиядә лалә үстерүче берничә йөз җитештерүче бар, бу – шактый төшемле кече бизнес.

Сүз уңаеннан, Татарстанда иң күп лалә үстерүче Лилия Зәйнуллина да уңышын ел саен арттырып бара. 2021 елда ул Апастагы теплицасында 3,9 млн данә лалә үстерсә, быел Апас һәм Питрәч районнарындагы теплицаларда әлеге күрсәткечне ике тапкыр диярлек арттырырга ниятли. Шалтыраткач, үзен чәчәкләрне күпләп алучы 10лап кеше көткәнен әйтте. «Сөйләшергә дә вакыт юк, эшнең ничек барганын шуннан аңлагыз инде», – диде ул.

Россия базарында лалә чәчәкләре мартның беренче атнасында 150 млн данәдән артык сатыла икән. Уртача алганда бер россиялегә елына 2–3 чәчәк бәйләме туры килә.

Гомумән алганда, Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматлары буенча, соңгы биш елда илдә чәчәк үстерү 68 процентка арткан. Әйтик, 2016 елда 200,8 млн данә чәчәк сатылса, 2021 елда бу сан 338,9 миллионга җиткән. Алексей Антипов быел да шул чама булыр, дип фаразлый. Ә менә Россельхозбанк бәяләмәсе буенча, илдә чәчәк җитештерү ел ахырына кадәр 500 млн данәгә җитәргә, ә базарда сатыла торган чәчәкләрнең 25 проценты үзебезнеке булырга мөмкин. Хәзерге вакытта бу күрсәткеч 17 процентны гына тәшкил итә.

- Голландиядән >> 34 процент
- Эквадордан >> 33 процент
- Белоруссиядән >> 9 процент
- Кениядән >> 8 процент
- Колумбиядән >> 6,6 процент

2023 елда кибетләрдә Россиядә, Көньяк Америка һәм Азия илләрендә үстерелгән гөлләр сатылачак, Төркия, Белоруссия, Әрмәнстан һәм Кытайдан кайтарылган гөлләмәләр артачак.

Соңгы биш елда Россиянең төп җитештерүчеләре һәм импортерлары түбәндәге чәчәкләрне үстерүгә игътибар бирә

РОССИЯДӘ ЧӘЧӘК ҮСТЕРҮ

2021 ел.................................**340 миллион** данә
2022 ел.................................**400 миллион** данә
2023 елга фараз......................**500 миллион** данә

6 март | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК» 16+
10.00, 23.00 «ДЕВУШКА СРЕДНИХ ЛЕТ» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «БИЧАРАКАЙ» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Моң чишмәсе» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Гаилә учагы» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» 16+
19.00, 00.15 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 Выставка «ТатАгроЭкспо-2023» 12+
21.05 «Соотечественники» 16+
23.50 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
00.05 «Если хочешь быть здоровым» 16+
00.40 «Ком сәгате» 16+
01.30 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «Муза... Музыка... Мозаффаров...» Телеочерк 16+
15.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Моң чишмәсе» 16+
17.30 «Гаилә учагы» 16+
19.15, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Гаилә учагы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Долгожданная премьера. В эфире «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Премьера. «Век СССР». 4-я серия. «Запад». Часть 1 16+
01.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Валерия Федорович, Маруся Климова, Надежда Лумпова, Алексей Демидов, Михаил Евланов, Владимир Кошевой. «ЛИМИТЧИЦЫ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева в телесериале «КАМЕНСКАЯ» 16+
03.50 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Конный спорт. «Dubai World Cup Carnival. Super Saturday». Трансляция из ОАЭ 0+
07.00, 10.05, 12.55, 14.20, 19.50 Новости
07.05, 19.15, 22.00, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.10, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.30 Смешанные единоборства. UFC. Александр Волков. Лучшее 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
14.25 «Громко» Прямой эфир
15.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/4 финала конференции «Восток». «Сибирь» (Новосибирская область) – «Авангард» (Омск). Прямая трансляция
17.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/4 финала конференции «Восток». «Металлург» (Магнитогорск) – «Автомобилист» (Екатеринбург). Прямая трансляция
19.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Балтика» (Калининградская область) – «СКА-Хабаровск». Прямая трансляция
22.25 Баскетбол 1х1. Лига Ставок – B1BOX. Прямая трансляция из Москвы
01.15 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. 1/4 финала. «Пермские медведи» (Пермь) – «Зенит» (Санкт-Петербург) 0+
02.45 Лыжный спорт. Фристайл. «Кубок Евразии». Ски-кросс. Трансляция из Миасса 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Лёгкая атлетика. Чемпионат России в закрытых помещениях. Трансляция из Москвы 0+

НТВ

04.55 Сериал «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «АУТСАЙДЕР» (S) 16+
22.00, 00.00 Боевик «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.45 Кирилл Сафонов, Анна Снаткина. «КРИМИНАЛЬНЫЙ ДОКТОР» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.25 «Давай разведёмся!» 16+
09.25 «Тест на отцовство» 16+
11.30 «Понять. Простить» 16+
12.35 «Порча». «Дань» 16+
13.10 «Знахарка» 16+
13.45 «Верну любимого» 16+
14.20 «Голоса ушедших душ» 16+
14.55 «УРОКИ ЖИЗНИ И ВОЖДЕНИЯ» 16+
19.00 «ТЕСТ НА ВЕРНОСТЬ» 16+
23.05 «Порча» 16+
23.40 «Знахарка» 16+
00.15 «Верну любимого» 16+
00.45 «Голоса ушедших душ» 16+
01.15 «ВОСТОК-ЗАПАД». 25-я – 28-я серии 16+
04.25 «Понять. Простить» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «НЕ ЗАБЫВАЙ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 00.50 «ТЕКУМЗЕ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.20, 18.20 «Специальный репортаж» 16+
14.05, 15.05 «КОТОВСКИЙ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.55 «Сталинград. Ни шагу назад!» Документальный фильм. 1-я серия. Премьера! 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Санкции против Югославии» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ПОСТАРАЙСЯ ОСТАТЬСЯ ЖИВЫМ» 12+
02.20 «ШЕЛ ЧЕТВЕРТЫЙ ГОД ВОЙНЫ...» 12+
03.50 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+
05.15 «Перелом. Хроника Победы» 16+

7 март | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК» 16+
10.00, 23.00 «ДЕВУШКА СРЕДНИХ ЛЕТ» 12+
11.00 «Азбука долголетия» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «БИЧАРАКАЙ» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Моң чишмәсе» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «О спорте, о семье, о счастье». К юбилею Шамиля Тарпищева 12+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
18.20 Выставка «ТатАгроЭкспо-2023» 12+
19.30 Хоккей. Кубок Гагарина.Матчи серии play-off. «Нефтехимик» – «Ак барс». Прямая трансляция 0+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 16+
00.15 «Соотечественники». Шамиль Тарпищев. Услышанный богом 16+
00.40 «Семь дней+». Гузель Яхина. Писатель, лауреат премий «Большая книга» и «Ясная Поляна» 16+
01.05 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Ватандашлар». Җавап итеп аваз салырмын. Ф.Яруллин 16+
12.05 «Күңелем назлары җырымда чагыла». Татарстанның халык артисткасы Флера Сөләйманова турында телеочерк 16+
15.30 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Моң чишмәсе» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20 «Күңелем назлары җырымда чагыла». Татарстанның халык артисткасы Флера Сөләйманова турында телеочерк 16+
19.15, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
21.25 «Күңелем назлары җырымда чагыла». Татарстанның халык артисткасы Флера Сөләйманова турында телеочерк 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Долгожданная премьера. В эфире «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Премьера. «Век СССР». 5-я серия. «Запад». Часть 2 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Валерия Федорович, Маруся Климова, Надежда Лумпова, Алексей Демидов, Михаил Евланов, Владимир Кошевой. «ЛИМИТЧИЦЫ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ» 16+
03.50 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
07.00, 10.05, 16.25 Новости
07.05, 14.45, 19.15, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.10 Специальный репортаж 12+
10.30 Смешанные единоборства. UFC. Пётр Ян. Лучшее 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/4 финала конференции «Восток». «Адмирал» (Владивосток) – «Салават Юлаев» (Уфа). Прямая трансляция
15.25 Еврофутбол. Обзор 0+
16.30 «Вы это видели?» 12+
17.30 «Ты в бане!» 12+
18.00 Смешанные единоборства 16+
20.30 Футбол. Лига конференций. 1/8 финала. «Лацио» (Италия) – АЗ (Нидерланды). Прямая трансляция
22.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Челси» (Англия) – «Боруссия» (Дортмунд, Германия). Прямая трансляция
01.55 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Бенфика» (Португалия) – «Брюгге» (Бельгия) 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Пари НН» (Нижний Новгород) – УНИКС (Казань) 0+

НТВ

04.55 Сериал «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.50 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «АУТСАЙДЕР» (S) 16+
22.00 Боевик «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.15 Премьера. «Диагноз: жизнь» 16+
01.15 Остросюжетный сериал «КРИМИНАЛЬНЫЙ ДОКТОР» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Скажи, подруга» 16+
06.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40 «Давай разведёмся!» 16+
09.40 «Тест на отцовство» 16+
11.45 «Понять. Простить» 16+
12.50 «Порча». «Замочная скважина» 16+
13.25 «Знахарка» 16+
14.00 «Верну любимого» 16+
14.35 «Голоса ушедших душ» 16+
15.10 «НЕПРЕКРАСНАЯ ЛЕДИ» 16+
19.00 «СОЛНЦЕ, МОРЕ И ЛЮБОВЬ» 16+
23.05 «Порча» 16+
23.40 «Знахарка» 16+
00.15 «Верну любимого» 16+
00.45 «Голоса ушедших душ» 16+
01.15 «ВОСТОК-ЗАПАД». 29-я – 32-я серии 16+
04.25 «Понять. Простить» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.40 «Герой 115». Документальный фильм 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 02.05 «БРАТЬЯ ПО КРОВИ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 18.20 «Специальный репортаж» 16+
14.05, 15.05 «КОТОВСКИЙ». 5-я – 8-я серии. 16+
15.00 Военные новости 16+
18.55 «Сталинград. Ни шагу назад!» Документальный фильм. 2-я серия. Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ЖЕСТОКИЙ РОМАНС» 12+
03.25 «ПОСТАРАЙСЯ ОСТАТЬСЯ ЖИВЫМ» 12+
04.30 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
04.55 «ДЕВУШКА С ХАРАКТЕРОМ» 12+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Мәгариф системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары **Поминов** Андрей Иванович **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүләре, күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Зенит» волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры (Казан шәһәре) **Брызгалов** Олег Георгиевич, «Динамо-Казан» хатын-кызлар волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры **Чернышов** Сергей Николаевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел»** медале белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе **Исланов** Роман Леонидович, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык буенча белгече **Кормильцев** Евгений Александрович, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Айдар авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Шәвәлиева** Лилия Нәкыйф кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Татарстан Республикасы Дәүләт академик симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенең клавишлы уен кораллары төркеме оркестр артисты **Әхмәтов** Эдуард Олеговичка, вокалчы артист (солист), Казан шәһәре Совет районының «Азино» балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең өстәмә белем бирү укытучысы **Баһавиева** Гүзәл Фирдәвес кызына, «Татарстан Республикасы Дәүләт академик симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенең тромбон төркеме концертмейстеры **Вәлиев** Руслан Рөстәм улына, «Габдулла Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасының дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты **Заһидуллина** Рәзинә Ирек кызына, «Әлмәт татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасының дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты **Хөснетдинов** Динар Вәзим улына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Бөтенроссия дәүләт телевидение һәм радио тапшырулары компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татарстан» дәүләт телевидение һәм радио тапшырулары компаниясе» филиалы телевидение мәгълүмат программалары хезмәтенең программаларны әзерләү һәм чыгару төркеме программа алып баручысы **Второв** Дмитрий Юрьевичка **«Татарстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Россиянең атказанган спорт мастеры, «Татнефть – Ак Барс» спорт-коммерциячел предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Ак Барс» хоккей командасы спорт блогы спортчы-хоккейчысы **Зарипов** Данис Зиннур улына, «Татарстан Республикасының Волейбол федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы башкарма директоры **Кәримов** Мансур Зәки улына **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЮГАЛМАСЫН ТОРМЫШ ЯМЕ!

Күңел төшенкелеге түгел! Эмоциональ «яну» турында сөйләгәндә, белгечләр шулай ди. Соңгы арада психологларга нәкъ менә шушы халәттән зарланып килүчеләр саны арткан. Эмоциональ «яну» нәрсәсе белән куркыныч? Аны ничек чамаларга? Ничек сакланырга?

Педагог-психолог, балалар психологы Регина ФӘХРИСЛАМОВА белән шул хакта сөйләштек.

:: Эмоциональ «яну» ни дәрәҗәдә куркыныч?

– Эмоциональ «яну» синдромы көннән-көн арта барган эмоциональ һәм физик арудан гыйбарәт. Ул, гадәттә, кешеләр белән эшләгәндә хисләргә чамадан тыш бирелүгә җавап рәвешендә барлыкка килә. Кешенең мондый халәте хәтта халыкара авырулар классификациясенә дә кертелгән. Бу синдромның нинди җитди авыру икәне шуннан аңлашыла инде.

:: Андый чакта кеше ничек үзгәрә?

– Авыру башланып кына килгән мәлдә кеше ярсучан, явызга әйләнә. Никадәр генә йокласа да, йокысы туймый, арыганлыгы бетми, тынгысыз йоклый, фикерләрен туплый алмый тилмерә, аның хәтере дә начарлана. Үз бәяңне төшерү, үз-үзеңне бар нәрсәдә гаепле итеп тою, апатия шулай ук кешедә әлеге синдромның башланып килүе турында кисәтергә мөмкин. Бу халәт озаккарак сузылган саен, кеше тормышында тискәре үзгәрешләр артканнан-арта бара. Ул эшенә салкын карый башлый, үзенең һәм хезмәттәшләренең хезмәтен түбәнсетә, үз эченә йомыла, кешеләр белән аралашудан кача. Эмоциональ «яну» синдромы яхшы ук тамыр җәйсә, кеше сәбәплесәбәпсез эш калдыра, бик еш «больничный»га чыга. Андый кеше еш кына баш авыртудан зарлана, аның кан әйләнеше системасы, калкансыман биз эшчәнлегендә хилафлыклар башлана. Бу билгеләрнең берсе генә күзәтелсә дә, кичекмәстән табибка, психологка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Эмоциональ «яну» куркынычы бигрәк тә кемнәргә яный?

– Җәмгыятьтә киеренкелек, стресска китерә торган шартлар арткан саен, эмоциональ «яну»чылар да күбәя. Соңгы арада безгә ярдәм сорап килүчеләр арасында да андыйлар шактый. Бу халәткә табиб, психолог, укытучы, социаль хезмәткәр, коткаручы кебек һөнәр ияләре тизрәк һәм ешрак бирешә. Җаваплы урыннардагы җитәкче, администратор кебек кешеләрнең, хуҗабикә һәм күп бала аналарының да баш бәласе ул. Күпсанлы тикшеренүләр нәтиҗәләренә ышансаң, хатын-кызлар арасында эмоциональ «яну» очраклары ир-атларга караганда ешрак очрый. Ул кешенең холык үзенчәлекләренә дә бәйле булырга мөмкин. Әйтик, перфекционист яки артык нык хискә бирелүче, кешеләргә «юк» дип әйтә белмәүчеләр арасында да бу күренеш еш очрый.

:: Гадәти арудан аны ничек аерырга?

– Арыган кеше, бераз ял итеп алуга, шундук рәткә килә, көче, энергиясе арта. Моның өчен аңа тәмле ашап, туйганчы йоклау да җитә. Эмоциональ яктан янган кешегә исә үз хәленә кайту өчен бик күп көч һәм вакыт таләп ителә.

:: Бу халәтне күңел төшенкелеге белән бутаучылар да шактый...

– Күңел төшенкелегенә бирелгән кеше тормышының бөтен өлкәләрендә яшәү ямен, тәмен югалта. Ул тормышында нидер үзгәртүне мәгънәсез дип саный. Эмоциональ «яну» кеше тормышының бер генә өлкәсендә, гадәттә, эше белән бәйле рәвештә барлыкка килә. Ул еш кына шушы тармакта салкынлык һәм ваемсызлык күрсәтә.



cdnstatic.rg.ru

«ЯНУ»ДАН САКЛАНУ ӨЧЕН

✓ Үз-үзегезгә, теләк-ихтыяҗларыгызга, максат-хыялларыгызга һәрчак игътибарлы булыгыз. Тегеләр яки бу авыру пәйда булса, вакытында чарасын күрегез.

✓ Үз өстегезгә артык зур бурычлар, чамадан тыш күп эш алмагыз. Кешеләргә «юк» дип әйтергә өйрәнегез.

✓ Эш белән ял арасында һәрчак баланс саклансын.

✓ Кайчак ялгызың калып, үзең генә ял итү, уй-фикерләреңне тәртипкә китерү дә файдалы.

Белеп тор!

Чәчкәләрнең нигә кирәге бар?

Халыкара хатын-кызлар көне якынлаша. Гүзәл затларыбызны бүләккә генә түгел, гөл-чәчәккә күмә торган көн бу. Әмма чәчәк бирүнең дә рәте бар. Бигрәк тә чәчкәләргә аллергиясе булган хатын-кызга мондый бүләк сайлаганда сак булырга кирәк. Бу очракта кайсы чәчәкләрне урап узарга? Иммунолог **Елена Латышева** ике кагыйдәне истә калдырырга киңәш итә.

Бүләк итәргә ярамый. Аллергиядән интеккән гүзәл затка лилия, гиацинт, хризантема, ромашка, гербера бүләк итәргә ярамый. Янәрак кына ОРВИ белән авырып терелгән хатын-кызга да мондый чәчәкләрне бүләк итмәү хәерле. Ник дигәндә, андый чакта сулыш юлларының лайлалы тышчасы ахыргача рәткә килеп бетмәгән була. Шуңа күрә хуш исле әлеге чәчкәләр аны ярсытып, кеше бик нык төчкерә башларга, күз яше агарга, борынына томау төшәргә мөмкин.

Бүләк итәргә ярый. Орхидея, альстромерия, эустома, роза, ирис, лалә, нәркис, флокс чәчкәләрен курыкмыйча

бүләк итәргә була. Алар һәр гүзәл затның күңеленә хуш килә. Мондый чәчәкләр аллергиядән интегүчеләргә дә кыенлык тудырмаячак.

Аллергия бирә торган чәчәк бүләк итсәләр... Мондый чәчәк бәйләмен ташларга ашыкмагыз. Чәчкәләрнең зыянын бетерү өчен, аларга су бөркергә кирәк. Бу алардагы иң төп аллерген саналган серкәне юкка чыгарачак. Чәчәк бәйләме торган өстәл өслеген дә дымлы чүпрәк белән сөртеп алу хәерле. Гөлләмәдә кыр чәчкәләре, матурлык өчен арыш, солы сабаклары өстәлгән булса, аларны да алып куярга кирәк.

Киңәш

ВАКЫТЫ ДА, ШИФАСЫ ДА ЧАМАЛЫ

Күпләр яраклылык вакыты чыккан даруларны да файдалана. Белгечләр исә моны зур хата дип кисәтә.

▸ Күзгә сала торган тамчылар. Яраклылык вакыты чыккан беренче көнне үк ташланырга тиеш. Чөнки файдасы бетә, анда бактерияләр үрчи башлый.

▸ Дарулы шешәне, ачылганнан соң, бер елдан да озаграк сакларга ярамый. Юкса аның эчендә сакланган дарулар ашказаны-эчәк трактында хилафлыклар китереп чыгарачак. Кайбер капсула, дарулар бик тиз кибә, һавадагы су парларын йотучан була. Шу шулай ук даруның файдасын киметәчәк.

▸ Инъекция ясау өчен кирәкле эремәләр. Яраклылык вакыты чыккач, аларда агулы матдәләр пәйда була. Әгәр инъекция өчен кирәкле эремә төсен үзгәрткән, тоныкланган икән, аны вакыты чыкмаган булса да, кулланырга ярамый.

▸ Витаминнар. Алар составындагы түбән молекуляр органик катнашмалар бик тиз таркала. Шуңа күрә яраклылык вакыты тәмамланып килгән чорга инде аларның файдалы үзлекләре юк дәрәҗәсендә була.

▸ Яраклылык вакыты чыккан нитроглицерин, инсулин, сыеклык рәвешендәге антибиотикларны эчү сәламәтлеккә генә түгел, кеше гомеренә үк куркыныч тудыра.

Сорау – җавап

:: Температура күтәрелгәндә, кәһвә эчәргә ярыймы?

Алсу ВАФИНА. Сарман

Сорауга гомуми практика табибы Юлия ХӘЙРУЛЛИНА җавап бирә:

– Юк, ОРВИ, ОРЗ белән авырган вакытта, гомумән, кәһвә эчәргә киңәш ителми. Ник дигәндә, ул тәнебезне сусызландыра. Шул рәвешле организм тагын да кыза, температура ныграк күтәрелә. Шуңа күрә температура күтәрелгәндә, үлән чәйләре, җылы морс эчү хәерлерәк.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ТАМЫРЫ НЫК БУЛСЫН

Яшелчә кәлшәсе үстерү – бик мавыктыргыч эш. Әмма үсентеләрнең сәламәт, нык булуы өчен байтак кына белем, тырышлык та кирәк. Бакча мәсьәләсендә мең дә берне белгән Әлфинур Нәҗметдинова белән укучыларыбызны борчыган кайбер сорауларга җавап бирергә булдык.

:: Борычларыма тишелергә вакыт инде. Әмма әле шытымнары күренми, нигә алай икән?

А. КАМАЛИЕВА.
Саба

– Орлыклар 10–14 көн эчендә тишелмәсә, болай эшләп карагыз. 2 стакан кайнар суга чәй кашыгы очында төелгән кызыл борыч һәм 2 тамчы йод кушып болгатыгыз һәм шуны туфракка сибегез. Бу ысул тишелмәгән орлыкларны «уятып җибәрә».

:: Помидорның кыйммәтле гибрид сортлы орлыкларын утырткан идем. Үсентеләр инде шактый үстеләр. Ләкин арада зәгыйфьрәкләре дә байтак. Аларны күчереп утыртудан мәгънә булырмы икән? Гомумән, күчереп утыртуның нindирәк серләре бар?

Нина ВАСИЛЬЕВА.
Казан

– Кыйммәтле гибридларның барлык шытымнарыннан файдаланырга кирәк. Ник дигәндә, зәгыйфь үсенте гадәти сортның көчле үсентесенә караганда барыбер мулрак уңыш бирәчәк.

Сере нидә дигәндә, бу эшне болытлырак вакытта, кичен башкару әйбәт. Кояшлы көннәрдә алар начаррак тернәкләнә. Күчереп утыртканчы, үсемлекне туфрагыннан саклык белән генә алып, тамырының өчтән бер өлешен өзәләр һәм аерым савытка утырталар. Тармакланып үссен өчен тамырын шул рәвешле кыскартырга кирәк. Күпчелек үсентене туфракка яфракларына кадәр күмеп куялар. Юкса ул бик тиз озыная башлый. Ә менә борыч кәлшәсен, нинди тирәнлектә үскән, шундый тирәнлеккә (яки 1әр сантиметр тирәнрәк) күчереп утыртудан да яхшысы юк.

vk.com

Шуннан соң үсентеләрне, кәгазь белән күләгә ясап, кояш нурларыннан сакларга кирәк.

:: Узган ел базардан сатып алынган кәбестә кәлшәләре бик начар уңыш бирде. Шуңа күрә быел аларны үзем үстермәкче булам. Ничек дөрес итеп үстерергә соң?

Наилә ГАБДРАХМАНОВА.
Балык Бистәсе

– Кәбестә кәлшәсен бүлмәдә бик яхшы итеп үстереп булмый, чөнки ул салкынча һаваны ярата. Яшелчә орлыгын апрельнең уннарыннан соң, көннәр җылыткач, теплицага кечкенә генә түтәл ясап чәчәләр. Түтәл көздән әзерләп калдырылган булырга тиеш. Чәчкәнче, туфракка марганцовкалы җылы су сибәсе. Түтәлгә төнгә полиэтилен каплап калдыру әйбәт. 2–3 көнгә бер тапкыр җылы су сибеп торырга кирәк. Теплицадагы һава температурасы көндез 15–17 градус, төнлә 8–10 градус булса, кәбестә гөрләп үсәчәк.

:: Үсентеләргә фильтр аша үткәрелгән су сибә башлаган идем. Әмма андый суда үсентеләр өчен файдалы матдәләр калмый, шуңа күрә аны сибәргә ярамый, дип ишеттем. Бу дөресме?

Галия НУРИӘХМӘТОВА.
Түбән Кама

– Юк, дөрес түгел. Киресенчә, үсентеләр өчен әйбәт су бу. Фильтр булмаса, суны савытка салып, 1–2 көн тотарга мөмкин. Сүз уңаеннан, үсенте өчен әчкелт су (10 л суга 1 торф сәдәфе яки 1 г лимон кислотасы салып) бик файдалы.

Ә инде иң яхшысы – кар, яңгыр суы. Ләкин зур шәһәрләр, сәнәгать предприятиеләреннән ераграк яшәүчеләр генә аннан курыкмыйча файдалана ала. Су температурасына килгәндә, ул 20–25 градус чамасы булырга тиеш. Үсентеләргә сибү өчен кайнатылган суны кулланырга ярамый. Ник дигәндә, кайнаганда, судагы кислород югала, ә бу үсентегә начар тәэсир итә.

Исеңдә тот!

КЕЛӘМДӘГЕ ТАПТАН КОТЫЛУ

Келәмдәге тапларны бетерү өчен, пыяла юу сыекчасын кулланырга мөмкин. Ул хәтта бик нык сеңгән таплардан да чистарта. Моның өчен сыекчаны тапка тамызып, өстенә иске сөлге салыгыз. Бер минуттан соң шуның аша үтүкләгез. Сөлгене алгач, келәмдәге тапның эзе дә калмавын күреп сөенәчәксез!

ЯБЫШКАН КӘГАЗЬДӘН ЧИСТАРТУ

Яңа савыт-сабага ябыштырылган кәгазьне тиз генә куптарып булмый. Сере бар. Кәгазьгә тырнактагы лакны бетерү сыекчасын тидерергә кирәк. Шундук кубып төшәчәк.

Саклау вакытын кара

Гадәттә без кремны беткәнче сөртәбез. Һәр әйбернең саклау вакыты була һәм ул банкада яки тюбикта күрсәтелә. Әмма әлеге саннарның ачылмаган кремга гына кагылуын онытмаска кирәк. Банканы ачкач, яраклылык вакыты кими. Кремны ачык килеш күпме сакларга мөмкин булуы ачылган банка рәвешендәге тамга белән күрсәтелә. Кремны кояшта калдырган очракта, саклау вакыты тагын да кими.

Бу кагыйдә башка бизәнү әйберләренә дә кагыла. Әйтик, ачылган тушьны 2 айдан артык сакларга ярамый. Шуннан соң кибә, төерчекләнә башлый. Иннек белән дә шулай – ирен кырыйларына җыела, хуш исен җуя...

Ә менә коры косметика әйберләре (румяна, пудра, тень) тиз генә бозылмый. Әйтик, «күләгә» «пластмасса»га әйләнгән кебек булса, пумалага йокмаса, өске катламын гына алып ташларга кирәк. Иң гади ысулы – скотч ябыштырырга да куптарып алырга. Шуннан соң бизәнгечне рәхәтләнеп кулланырга.

Хуҗабикәгә

БОРЧАК ПЕШСЕН

Борчак ашы яки ботка әзерләү өчен плитә янында байтак кына вакыт уздырырга туры килә. Кайнар су салып, кыска дулкынлы мичтә 3–4 минут тотсагыз, борчак бик тиз пешәчәк.

Бәйрәм табынына

КАРА КАРЛЫГАНЛЫ ТОРТ

Сиринә МИҢНЕГАЛИЕВА рецепты

Кирәк: *200 г шоколадлы печенье, 70 г атланмай, 400 г йомшак «сливочный» сыр, 300 г куертылган сөт, 3 йомырка, 5 йомырка агы, 5 аш кашыгы шикәр пудрасы, 1 аш кашыгы желатин, 1 стакан катырылган кара карлыган.*

Печеньены ваклыйбыз. Шуңа атланмайны эретеп салабыз. Болгатып, тортның аскы катламы рәвешенә китерәбез.

Сыргa йомырка салып күпертәбез. 1/3 өлешен читкә куеп торабыз. Калганына куертылган сөт өстәп, болгатабыз. Катнашманы печенье өстенә тигезләп җәябез. Аннан соң йомыркалы сырны урнаштырабыз. Газ мичендә 160 градуста 50 минут пешерәбез. Желатинны җылы суга салып болгатабыз. «Су мунчасы»нда эрегәнче тотабыз. Шикәр пудрасына йомырка агы салып күпертәбез. Шуңа карлыганның яртысын һәм желатин салып болгатабыз да катнашманы торт өстенә сылыйбыз. Тортны калган карлыган белән бизәп, суыткычка куябыз.

Белсәң, зыян итмәс

Хуш исле һәм тәмле!

☑ Савытына берәр кисәк әфлисун кабыгын салып куйган очракта, чәйгә бик тәмле хуш ис сеңәчәк.

☑ Табынга куяр алдыннан какаога берничә тамчы лимон согы өстәргә мөмкин. Эчемлек искиткеч тәмле булачак.

☑ Томат согына бераз гына лимон согы һәм бал өстәгәндә, үзенчәлекле эчемлек барлыкка килә. Аны бигрәк тә балалар ярата.

ДИН ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫ ОЛЫЛЫЙ

8 Март бәйрәме җитәрәк гүзәл затларны – хатын-кызларны күбрәк телгә алу табигыйдер. Аллаһы Тәгалә хатын-кызларга бик күп өстенлекләр биргән. Алар – гаилә учагын саклаучы, иргә – таяныч, илгә матурлык һәм батырлык бүләк итүче. Ислам динендә хатын-кызларга мөнәсәбәт нинди?

Бу һәм башка сорауларга җавапны Артур хәзрәт ГАБДУЛЛИН белән эзләдек.

:: Хәзрәт, ислам динендә хатын-кызның урыны нинди?

– Хәзерге заманда, телевидение, интернет, радио, социаль челтәрләр аша булсынмы, халыкка хатын-кызларның ислам динендә хәлләре авыр булуын аңлатырга тырышалар. Янәсе, исламда хатын-кызларга бернәрсә дә ярамый, мөселман гаиләсендә яшәгән гүзәл затның тормышы – төрмә. Менә шундый пропаганда бара. Коръәнгә игътибар итсәк, анда 114 сүрә. Шулар арасында «Ниса» («Хатыннар») дигән сүрә бар. Аллаһы Тәгалә Коръәндә хатыннар турында тулы бер сүрә җибәргән. «Ирләр» дигәне юк анда. Чынлыкта, ислам дине хатын-кызга нинди мөнәсәбәттә булырга кирәк икәнен өйрәтә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: «Сезнең арада иң хәерлесе – үз хатынына яхшы мөнәсәбәттә булучылар». Ислам дине хатын-кызны яратырга, сакларга, хөрмәт итәргә куша. Шул ук вакытта ирнең нинди булуы да хатын-кызларыбызга бәйле.

Әйткәнебезчә, Изге китапның аерым бер өлеше хатын-кызларга багышланган. Аллаһы Тәгалә аларның дәрәҗәсе нинди булуын әнә шулай күрсәтә. Хатын-кызга гына бу дөньяга яңа кеше китерү мөмкинлеге бирелгән. Икенчедән, пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләре әни, апа, сеңел, хатыныбызга бик яхшы мөнәсәбәттә булырга өйрәтә. Сүз, гамәл белән кимсетмәскә, зыян китермәскә өнди. Хәдисләрне укып караган кеше ислам динендә хатын-кызның дәрәҗәсе зур булуын аңлар.

:: Хәзер дилбегә хатын-кыз кулына күчеп бара кебек...

– Хәзерге заманда рольләр алмашына. Интернет, телевидение аша пропаганда бара. Төрле юнәлешләр бар, мәсәлән, феминизм. Алар хатын-кыз бәйсезлеге өчен тырыша янәсе. Ләкин алай булмый. Хатын-кыз белән ир-ат аерым яши алмый, алар – берберсен тулыландыручы. Камил мөнәсәбәтләр өчен икәү кирәк. Аллаһы Тәгалә – аларны бер-берләре өчен бар итүче. Хак динебез кушканча, өйрәткәнчә яшәргә кирәк. Шушы агымнар тәэсирендә күп кенә хатын-кызлар ирләре өстеннән идарә итә, аларны басып яши. Хатын-кыз сүзенә ияреп, ир-ат үзен ир иткән сыйфатларын югалтып, чүпрәккә әйләнә дә куя. Халыкта да юкка гына, ир – баш, хатын – муен, диелми. Баш кай якка борылса, муен да шул юнәлешне ала.

:: Хатын-кызларда нинди сыйфатлар өстенлек итәргә тиеш?

– Тыйнаклык, оялчан булу, иренә буйсыну кирәк. Бу очракта Аллаһы Тәгалә рөхсәт иткәннәргә буйсыну турында сүз. Гүзәл затлар ярдәмчел, иренә терәк булсын, юл куя белсен. Безгә – ир-атларга тәэсир итә торган затлар сез. Ирне ир иткән дә, юк иткән дә – хатын.

:: Хатын-кызларның теле тик тормый инде. Кайсыдыр очракта аңа хәләлен тыңламаска рөхсәт ителәме?

pinterest.com

ГАЙШӘ АНАБЫЗНЫҢ ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗНЕҢ (С.Г.В.) БҮТӘН ХАТЫННАРЫНА ХАС БУЛМАГАН ӨСТЕНЛЕКЛӘРЕ

- ➤Пәйгамбәр (с.г.в.) аннан башка гыйффәтле кызга өйләнмәгән.
- ➤Гайшәне аклап, Аллаһы Тәгалә аять иңдергән.
- ➤Җәбраил фәрештә аның ефәк тукымадагы сурәтен Мөхәммәдкә (с.г.в.) күрсәткән һәм: «Аңа өйлән! Ул – синең тормыш иптәшең!» – дигән.
- ➤Гайшә аның каршында ятканда, пәйгамбәр (с.г.в.) намаз укыган.
- ➤Пәйгамбәр (с.г.в.) башы Гайшәнең тезендә чакта, Аллаһ аның җанын алган.
- ➤Пәйгамбәр (с.г.в.) Гайшә бүлмәсендә күмелгән.

– Хатын-кыз кабыргадан яратылган. Кабырганы турайта башласаң, сындырырсың. Димәк, аны турайтып булмый. Ир-ат хатын-кызның табигатен аңлап бетермәскә дә мөмкин. «Ник болай әйтте? Ник болай эшләде икән?» дигән сораулар туа ала. Хатын-кызның бөтен сыйфатларын аңлау мөмкин түгел. Шуңа күрә дә кайсыбер вакытта ир-атларга да сабырлык күрсәтергә кирәк. Тел тик тормау да шуңа керә. Хатын-кызларда киң таралган, күп вакытта зыянлы сыйфат та ул. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Миңа җәннәт күрсәтелде. Анда күбесе мескеннәр иде. Җәһәннәмне күрдем, анда күпчелек хатын-кызлар иде», – ди. Ник әлеккәннәр? Ирләре игелек кылган саен, көннәрнең берендә күңелләренә ярамаган сүз ишетеп, гамәл күреп, ирләренә: «Синең миңа гомереңдә дә яхшылык күрсәткәнең юк», – дип әйткәнгә икән. Хатын-кыз – ир-атны тулыландыручы. Син ансыз барыбер яши алмыйсың.

Тыңламаска дигәннән, әйтик, ире хатынга Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәне эшләргә куша икән, хатын аны тыңламаска хокуклы. Киресенчә, изгелеккә өндәп тә тыңламаса, дөрес булмас.

Хикмәтле сүз

- «Адәм балаларының җирдә һәм диңгездә кылган әшәкелекләре сәбәпле, табигать күренешләре бозылыр».
- «Дөнья ул – ахирәтнең кыры, кеше бу дөньяда нәрсә чәчсә, шуны ахирәттә урачак».
- «Фани дөньяга артык бирелмәгез. Дөнья байлыгының колларына әйләнә күрмәгез!»
- «Кешеләргә ярыйм дип яшәгән кеше иң азакта кешеләргә дә, Аллаһы Тәгаләгә дә ярый алмас».



islam.ru

Сорау – җавап

Җаваплар Рамил хәзрәт Юнысның социаль челтәрдәге сәхифәсеннән алынды.

? Сәдаканы мөселманнарга гына бирергәме? Башка диндәге кешегә бирергә ярыймы?

– Беренче чиратта мөселманга бирелә. Әгәр дә фәкыйрь кеше сезнең ярдәмгә мохтаҗ икән, нинди диндә булуына карамастан, аңа да бирергә ярый.

? Иремнең әниләренә кайтасым килми. Күңел тартмый. Бу миңа гөнаһмы? Аларның миңа начарлык кылганы юк. Әмма икейөзлеләнеп кайтасым килми...

– Һичшиксез, кайтырга кирәк! Бу – сезнең күңел ярасы, психологик җәрәхәтегез. Яисә ник якынаюдан куркасыз, яисә билгеле бер типтагы кешеләр сезне этәрә. Туганлык җебен һәм ирегез белән араны суытмас өчен, кайтырга, түзәргә кирәк.

? Мәчеткә җомгага йөрим. Атна ахырында спиртлы эчемлек эчәргә туры килә...

– Намазны тиешле дәрәҗәдә һәм барысын да укымыйсыз, димәк. «...намаз фәхеш эштән дә, ярамаган эшләрдән дә укучыны тыя, намаз – әлбәттә, Аллаһ зекерләренең иң зурысы, Аллаһ сезнең ни эшләгәннәрегезне белә», – диелә «Үрмәкүч» сүрәсендә. Намазны өстән-өстән генә уку нәтиҗә бирми. Сыйфат өчен эшләргә кирәк.

Гыйбрәт ал!

Кәрзин

Үсеп җиткән бер егет, өйләнеп, хатыны белән төп нигездә яшәп кала. Әнисе үлеп киткәнгә күрә, аны әтисе үзе генә ун яшеннән үстерә, алар белән яши торган була. Егет әллә ваемсызлыгы, әллә киленнең котыртуы сәбәпле, әтисенә карата суына башлый. Һәм, әлбәттә, эти дә моны сизә. Тора-бара ул үзенең кирәксез икәнен аңлый. Шулай итеп, көннәрнең берендә улына шундый сүзләр белән мөрәҗәгать итә:

– Газиз улым! Йөрәгем сизә, миңа күп калмаган. Сезнең тынычлыкны алып, сезгә авырлык китереп яшисем килми. Үлем көтеп утырырга теләк юк. Шуңа күрә син тал чыбыгыннан зур кәрзин яса да мине шунда утырт. Аннары, тау өстенә алып менеп, шунда ташла. Шулай итеп мин үлеп китәрмен, сезне дә килен белән авырлыктан коткарырмын.

Бу сүзләрне ишеткән егет, хатыны белән киңәшләшеп, картайган әтисеннән котылырга була. Ул агач ботакларыннан зур гына кәрзин үрә, әтисен шул кәрзингә салып, тау башына күтәрелә. Кәрзин белән бергә әтисен ыргытам дигәндә, әтисе:

pinterest.com

– Улым, кәрзинне үзеңә калдыр. Килер бер көн, сиңа да кирәге чыгар. Синең улың кәрзин ясап, интегеп тормас. Сине шушы кәрзингә генә салып ташлар, – ди.

Әлеге сүзләрне ишеткән егет этисенең нәрсә әйтергә теләгәнен аңлый. Эшләргә теләгән эшеннән тәүбә итеп, әтисен өйгә алып кайта. Соңгы сулышына кадәр хөрмәт күрсәтеп тәрбияли.

Февраль ыгы-зыгылары аниме җанатарларының да тынычлыгын урлаган булса кирәк. «ВКонтакте» социаль челтәрендәге төркемнәрнең берсендә «рёданчылар»: «Әлеге берләшмә сәясәт, дин һәм милләтчелеккә бәйле түгел, без Россия законнарын бозарга өндәмибез», – дип язып куйганнар.

Шул ук социаль челтәрдәге төркемнәрнең берсенә нигез салучы «рёданчы» Сеня Алмутов дигән кеше дә, җыелып, йодрык уйнатучыларга аларның берниндә катнашы булмавын аңлатырга тырыша:

– Бу хәрәкәтнең лидерлары да, идеясе, максаты да юк. Бездә берниндә депрессия чалымнары да юк, без начарлык пропагандаламыйбыз, өстәвенә көч куллану һәм җәберләү яклы түгелбез.

«Үрмәкүч»ләрнең Казандагы «оя»сына күз салып өлгереп булмады. Тоткарлаулардан соң «рёдан»ның башкаладагы телеграм-сәхифәсе юкка чыкты. Аны булдырган кеше бары тик бу хәрәкәткә берниндә катнашы булмавын әйткән һәм кешеләрне төс-кыяфәткә карап кына бәяләргә ярамый дип өндәгән.

«Үрмәкүч»ләр турындагы яңалыкны Росмолодежь башлыгы Ксения Разуваева да шәрехләде. «Без ачыклаганча, «Рёдан» – берничә ел элек барлыкка килгән аниме-берләшмә ул. Үрмәкүч сурәте төшерелгән нәрсәләр исә – яшьләр арасында популяр булган брендның элеккеге коллекциясе генә. Аның берниндә дә формаль булмаган юнәлешкә катнашы юк», – дигән ул.

Ә менә Куркынычсыз интернет лигасы директоры Екатерина Мизулина әлеге хәрәкәтнең популярлашуында социаль челтәрләр һәм мәгълүмат чараларын гаепләде.

– «Рёдан» тарафдарлары яңгырдан соң калкып чыккан гөмбәләр кебек пәйда булды. «Хайп» һәм теләсә нинди мәгълүматны тарату нәтиҗәсе инде ул, – дигән фикердә ул. – Аңлашыла, «Рёдан» – депрессив-агрессив субкультура. Гомумән, аниме-субкультура деструктив санала. Яшьләрнең энергиясе артык күп, алар аны кая куярга белми.

Кыскасы, мәсьәлә үрмәкүч пәрәвезедәй, буталчык. Асылда, монда бер гаебе булмаган хәрәкәтне гаепле итеп калдырырга теләгән провокаторлар кулы уйнарга мөмкин, дигән шик тә бар. Шул ук вакытта яшьләрнең йодрык уйнатулары мәйдан бүлешкәннән түгел, ә, бәлки, үзгә киенгән, үзгә булганга күрә «гадәти» саналганнарның килеп бәйләнүләреннән дә булырга мөмкин бит.

Ата-аналарга нишләргә?

Әлбәттә, түрәләр борчылуы да, җәмәгатьчелекнең ыгы-зыгысы да ата-аналарныкына җитми инде. Төп кайгыручылар – алар. Балаларны ничек сакларга? Тискәре йогынты ясарлык агымнардан ничек алып калырга? Тыелган һәрвакыт татлы түгел икәнне аңлатып буламы? Психолог Галия Гыймадиевадан шул хакта сораштык.

– Кешенең кемгәдер кирәк һәм теге яисә бу төркем, юнәлеш, бергәлеккә булу ихтыяҗы бар. Бу табигый. Балалар өчен беренче «төркем» ул – аның гаиләсе. Бала гаиләдәгеләргә охшарга тырыша, алар кебек булырга тели. Әмма үсә барган саен барысы да үзгәрә. Охшашлык, тиңдәшләрне ул инде тышкы дөньядан эзли, – ди белгеч. – Әлбәттә, бик үк имин булмаган төркемнәр бар. Аларны деструктив дибез. Алар психиканы, сәламәтлекне бозуга юнәлдерелгән. Төп куркыныч та әнә шунда. Чынбарлык шулай корылган: берәү дә, балам теге яисә бу юнәлешкә кереп китмәс дип, 100 процент гарантия бирә алмый. Тик без, ата-аналар, кайбер нәрсәләргә йогынты ясый алабыз. Алар баланы үзгәртә алмый. Әмма балалар ата-анага ышана, аларның бала алдында абруе, ике арада җылы мөнәсәбәт бар икән, тәэсир итеп була әле.

Ата-анасы белән элемтәсе булмаган буын тышкы дөньяның тискәре факторларына ешрак дучар була, дигән фикердә психолог. «Яхшы, дөрес мөнәсәбәтләр балага ныклы үзбәя, үзеңне яклый алу мөмкинлеге бирә, андыйлар кирәк урында «юк» дип әйтә белә. Кибәкне бөртектән аералар, кыскасы», – ди Галия Гыймадиева.

Психологның ата-аналарга да киңәше бар. Беренчедән, баланың ниндидер субкультурага кушылганын күрәсез икән, тынычланырга, субкультураның асылын аңларга, кыйммәтләрен өйрәнергә. Икенчедән, баланың ихтыяҗлары канәгатьләндерелгәнме, юкмы – шуны ачыкларга. Әйтик, гаиләдә барысы да бик тыныч, тотрыклы, ә бала кинәт экстремаль юнәлешләргә йөз борды, ди. Тыныч мохиттә бу хакта сөйләшү, фикер алышу мөһим. Бала субкультура турында үзе сөйләсен, аңлатсын.

– Яшүсмерләр үзләрен иштетергә тели. Бу – табигый ихтыяҗ. Ата-ананың шундук шелтәләве, ябырылуы баланы куркытырга, читкә этәрергә мөмкин, – ди белгеч.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

P.S. *Язма теге яисә бу юнәлешне пропагандалау максатыннан әзерләнмәде.*

* Россиядә тыелган экстремистик хәрәкәт.

Сан

2022 елда Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы формаль булмаган яшүсмерләр берләшмәләре һәм балигъ булмаганнар катнашында (йә алар тарафыннан) **736** җинаять очрагын теркәгән. **2021** елда бу сан **694** иде.

Министрлык мәгълүматлары буенча, **2023** ел башына полициядә исәптә яше **18**гә җитмәгән **2,4** меңләп кеше тора, шулар арасында **192**се – формаль булмаган яшьләр төркеме катнашучылары, **70**е – Россиядә тыелган экстремистик хәрәкәт идеологиясе белән кызыксынучылар.

БУ ХАКТА НИ УЙЛЫЙЛАР?

Тимур СӨЛӘЙМАНОВ, «Алдынгылар хәрәкәте» оешмасының республика бүлеге җитәкчесе, Татарстан Рәисе ярдәмчесе:
– Әлбәттә, бу – безнең өчен җитди сигнал һәм ул «Алдынгылар хәрәкәте» кебек хәрәкәтнең хәзер аеруча да кирәк булуын дәлилли. Ул хәрәкәт тормышта үзен тапкан яшүсмерләр өчен генә түгел, һәр яшь кешене колачларга, массакүләм булырга тиеш. Иң элек ул хәрәкәт кайда яшьләр – шунда оешырга тиеш. Хәзерге вакытта онлайн мохиттә сыйфатлы итеп эшләргә кирәк. Яшүсмерләр, яшьләр виртуаль дөнья белән чынбарлыкны әллә ни аермый. Алар өчен болар икесе дә – үз ихтыяҗларын канәгатьләндерергә мөмкинлек бирә, үзләрен күрсәтә, аралаша торган урын. Онлайн эшчәнлекне көчәйтергә кирәк.

Айгөл ГАБДРАХМАНОВА, «Сәләт» яшьләр үзәге директоры:
– Илебез, республикабыз өчен хәзерге вакытта балалар һәм яшьләр белән эшләү актуаль юнәлеш булып кала. Без балаларны тискәре оешмалардан, зыянлы эшчәнлектән сакларга телибез икән, начарлыктан читләшеп, моның ни өчен әйбәт түгеллеген аңлатырга, яхшылыкка юнәлтергә кирәк. Бу безнең эштә иң төп кагыйдә булырга тиеш. Балаларга никадәр күбрәк альтернатива, сайлау мөмкинлеге бирәбез, шулкадәр күбрәк балаларны, яшьләрне сыйфатлы, яхшы юнәлешкә җәлеп итәчәкбез. Хәзерге көндә республикада бик күп оешмалар бар, алар төрле юнәлештә эшли.

Гаиләдән дә читкә китә алмыйбыз. Гаиләдәге тәрбия – нигез, база. Ата-аналар белән эшчәнлекне көчәйтергә кирәк. Моны эшләр өчен ата-аналар берләшмәләре булдыру мөһим. Балалар үз вакытын күпләп уздыра торган җирләрдә – бакчалар, мәктәп һәм башкасы – тәрбия эшенә зур игътибар бирергә кирәк. Ул тәрбия эше укудан тыш алып барыла торган бер чара булып кына калмаска тиеш. Моның да бер системага әверелүе мөһим.

Альберт БИКБОВ, блогер:
– Меңләгән яшүсмернең сәүдә үзәкләрендә сугышуларының сәбәбе – стресс күрсәткеченең гаять зур булуы. Яшьләр генә түгел, бөтен ил бу халәттә. Әмма яшьләрдә ул, гормональ сәбәпләр аркасында, көчлерәк чагыла. Ул җыела-җыела да, нәтиҗәдә, кая да булса, нәрсәгә дә булса чыгарга тиеш бит. <...> Иң мөһиме – пар чыгару бит. <...> Даими неврозның кайчан да булса, ничек тә булса чыгарга тиешлеге көн кебек ачык. Шуңа теләсә нинди чаралар эзлиләр дә инде.

(«Телеграм» социаль челтәрендәге сәхифәсеннән)

ХӘЙРИЯЧЕ ГӨЛНАЗ:

«ЯРДӘМ УРЫНЫНА АКЧА СОРАУЧЫЛАР БАР»

Гомерне юкка әрәм итәргә ярамый! Казанда яшәүче 38 яшьлек Гөлназ Мифтахова әнә шулай ди. Кулына онкологка юллама тоттыргач, тормышка бөтенләй башкача карый башлый ул: күктән җиргә төшә. Үз эчендә генә бикләнеп яшәмичә, башкаларны да кайгыртырга сүз бирә.

– Мин элек тә кешеләргә булышырга тырыша идем. Җае чыкканда, ярдәм сораган кешеләрне мөмкинлегемә карап сөендердем. Кияүгә чыгып, балалар үстерә башлагач, тормыш мәшәкатьләренә чумдым. Ипотекага алган фатир, кечкенә балалар, тегесе кирәк, монысын табасы бар, – дип сөйли Гөлназ үзе турында.

Без аның хәйриячелек белән шөгыльләнеп, кешеләргә булышуы хакында очраклы гына белеп алдык. «Ватаным Татарстан»ның социаль челтәрдәге бер төркеменә аның хакында хәбәр калдырганнар иде. Үзенең сөйлисе килмәсә дә, Гөлназның зур эш башкарганын белдек. Авыр хәлдә калган кешеләргә киемнәр җыеп, аларны юып, үтүкләп, мохтаҗларга илтеп тапшыра икән. Алучы табылмаса, хуҗасының рөхсәте белән аларны сатып, шул акчаны яман чир белән көрәшүче ике бала өчен ризык катнашмасы алуга тота.

– Баштарак минем бу гамәлемне ирем дә аңламады. Ник кирәк инде сиңа кеше искелəрен җыю, дип тә аптырый иде. Йортсыз кешеләр туңмасын дип кайгыртам. Күбесен якыннан беләм. Ни кирәген сорап, үзләренә илтеп бирәм. Иске генә булса да машинам бар. Шунда төйим дә чыгып китәм. Ирем дә, балаларым да, туганнарым да мине бу эшне ташларга күндерә алмадылар. Хәзер инде үзләре дә бик теләп булыша, – ди Гөлназ.

Кешеләргә булышудан да рәхәт әйбер юк шул ул. Булышкан кешеңнең йөзендәге елмаюны күрү дә ни тора! Гөлназ да, кеше рәхмәтләре белән яшим, ди.

– Күптән түгел интернетка бер артык өс киемен сатарга дип куйдым. Бәясе кыйммәт түгел – 100–200 сум тирәсе генә. Алырга дип бер хатын килде. Сөйләшеп киттек. Ире үлгән, өч баласын берүзе үстерә икән. Бу хакта белгәч, ничек акча сорыйсың инде? Сез ул хатынны күрсәгез иде! Шатлыктан елап ук җибәрде. Ә без байлык дибез, бер күзәнәге киткән киемне тегеп тә тормыйча чүпкә ташлыйбыз. Ризыктан йөз чөерәбез. Ә бит арабызда бик авыр хәлдә яшәүче кешеләр күп, – ди Гөлназ. – Кешеләрнең өйләренә барып йөри башлавыма 2 ел гына әле. Әмма шушы вакыт эчендә зарланмаска, уфтанмаска өйрәндем. Алар белән үземне чагыштырам да шөкер итәм. Ә бит мин үзем дә әллә кем түгел. Гади тәрбияче, ипотека түлим. Өстемдәге курткам да искерде инде. Әмма яңасын

алып кияргә ашыкмыйм әле, ул акчага башка берәүне сөендереп булыр дип уйлыйм. Мин тормышның кадерен, яшәүнең акчадан гына тормавын, әле бу җирдә шәфкатьлелек эшләп тә яшәп булганын аңладым. Теге вакыттагы кебек… Тормышны үзгәрткән 2020 елны мин әле дә оныта алмыйм.

Ул вакытта Гөлназга табиб яман шеш диагнозын куя. Тизрәк онкология диспансерына җибәрәләр. Ул чактагы кичерешләрен үзе генә белә ул. Өйдә ике бала, бакчада күпме сабый, якыннары бар. Әле бит тормышның башланып кына килгән мәле! Табибка кереп тикшеренеп, анализлар тапшырган Гөлназ сүз бирә: барысы да яхшы булса, намазга басар һәм кешеләргә яхшылык эшләр идем! Бераз хәл керүгә, бер хәйрия фондында эшләүче дусларыннан авыр хәлдә калган кешеләрнең адресларын ала һәм эшкә тотына. Хәзер инде ул кешеләрне эзләми, аның үзен эзләп табалар. Гөлназ исә ярдәм итүдән туктарга җыенмый.

– Мохтаҗ кешеләр арасында да төрлесе бар. Берәүләр биргәнеңә йөз кат рәхмәт укыса, кайберәүләр сүгеп тә ташлый. Киемне дә сайлап кына алучысы бар. Азыктөлек урынына акча бирегез дип сорыйлар. Кешеләргә ярау кыен. Шөкер, рәхмәтлесе күбрәк, – ди ул. – Мин һәрвакыт үземне авыр хәлдә калган кеше урынына куям. Йөри алганыма, күзләрем күргәнгә сөенәм. Ашарга ризык, торыр җирем, яраткан эшем бар, дим. Без бит бу җирдә кунак кына. Үләсебезне дә уйларга кирәк. Савап җыеп калырга ашыгыйк дип яшим. Кайчак якын кешеләрем дә, үзеңә файда эзлисең, диләр. Хәйриягә дигән акчаның бер тиенен дә тотмыйм. Беләсезме, шушы эшләргә тотынгач, тормышым да үзгәрде, акчам да җитә башлады. Һәр көнгә сөенеп, шатланып яшим. Берәүгә дә ачу сакламыйм. Сүксәләр дә, бармак төртеп күрсәтсәләр дә, исем китми инде хәзер. Иң мөһиме – күңелемә тынычлык таптым. Миңа шулай рәхәт. Аллаһы Тәгалә шушы хисләрдән аермасын гына!

АНА КАДЕРЕ

Гасыр яшьтәше

Азнакайда яшәүче Гыйльменур Җәләева шушы көннәрдә 100 яшен тутырды. Гомере буе кешеләргә бары тик яхшылык кына теләп яшәгән әбекәйнең, шөкер, картлыгы матур уза. 3 бала тәрбияләп үстергән, 7 онык, аларның 12 баласына сөенеп яши ул. Барысын да аңлый, иң мөһиме – тәрбияләгән өчен рәхмәтен әйтеп тора. Улы Илдар белән килене Ләлә тәрбиясендә яши Гыйльменур әби.

Йөзьяшәрнең үткән гомере хакында без Ләлә ханым белән сөйләштек.

– Безнең әни Буралы авылында туып үсә. Мәктәптә яхшы укый, урта белем алгач, дәүләт иминияте системасында бухгалтер булып эшли. 1942 елның гыйнварында ул фронтка китә. Радист була. Әни Брянск шәһәрен, Украина, Румыния, Чехословакия, Болгарияне фашистлардан азат итүдә катнаша, – ди Ләлә ханым. – Фронтта күрсәткән батырлыклары өчен тапшырылган бүләкләре белән ул да, без дә горурланабыз.

Туган якларына әйләнеп кайткач, кызны Буралы авыл советын җитәкләргә куялар. 1946 елда ул авылдашы Вәгыйзгә кияүгә чыга. Әмма сугыштан кайткан иренең гомере озын булмый, икенче улы туар алдыннан ул бакыйлыкка күчә. Тормыш дәвам итә. Илгиз һәм Илмир исемле уллары белән Гыйльменур апа тагын кияүгә чыга. Габделбәр абый белән аларның уртак балалары – игезәк уллары Ильяс белән Илдар туа.

– Шул Илдарның хатыны инде мин. Илгиз абый Мәскәүдә, шуңа еш кайтып йөри алмый. Илмир абыебыз вафат инде. Иремнең игезәге Ильяс гаиләсе белән Түбән

Камада яши. Без Азнакайда калгач, башта үз әниемне карадык. Каенанамны тәрбияләгәнебезгә 2–3 ел гына әле. 97 яшенә кадәр үзен-үзе карады ул. Бакчага да йөри иде әле. Бөтен нәрсәне үзе утыртты, – ди Ләлә ханым.

Гыйльменур әби беркайчан да дару эчмәгән. Үлән җыеп, шифаны шуннан тапкан. Чәйләрне дә үзе ясый торган булган. Үзе ясаган дару белән якыннарына да ярдәм иткән.

– Әни кебек кеше башка юктыр ул. 40 ел бергә яшәп, мин аннан бер авыр сүз ишетмәдем. Ул хәтта кычкырып та сөйләшмәс иде. Бу гаиләгә кияүгә килгәч тә, яхшы кешеләргә эләктем, диделәр, – ди Ләлә ханым. – Әни туры сүзле ул. Беркайчан да чәчәкләп сөйләшеп тормас. Яшьрәк вакытта иремнән зарланып, әни янына килдем. Әйтәсе килә бит инде. Илдарның соң кайтуын, көнләшүемне әйтәм. Шунда әни: «Мин бит сине көчләп кияүгә бирмәдем, улыма үзең чыктың. Торасың килсә, тор», – диде. Шушы сүзе җитте. Кая башка зарлану! Ир белән араны көйләдем. Әни миңа гел киңәшен биреп торды. Кычкырып талашмагыз, күршеләрегез ишетмәсен, өйдәгене кеше белмәсен, дияр иде. Алтын киңәшләр бит бу сүзләр. Хәзер инде үзем – 62 яшь. Әнинең никадәр акыллы, төпле кеше булганын күптән аңладым.

Гыйльменур апа улларына да дөрес тәрбия бирә. Кешелекле итеп үстерә ул аларны. Ләлә ханымның үз әнисе, авырып, урын өстендә ята. Мәшәкатьнең күбесе Илдар абый җилкәсенә төшә.

– Илдарның әнигә булган мөнәсәбәтен күреп шаккаттым. Ничек итеп мин аның әнисенә начар була алыйм ди. Күпләр миңа, олы кеше тәрбияләү кыен инде, каенанаң бигрәк озак яшәде, дип тә әйтә. Туйгансыңдыр инде, дип тә куялар. Җавабым бер: җирдә урын җитәрлек. Әниебез яшәсен генә әле. Ул барда мин ятим түгел, аннан күпме җылы алам. Ул булганда, шундый рәхәт. Бөтенебезгә берәү генә бит ул, – ди Ләлә ханым. – Әниебез 2020 елда коронавирус эләктерде. 97 ел эчмәгән даруны шунда эчте инде. Дару капмыйм дип тә киреләнде. Шөкер, элек сәламәт яшәгәч, авыруны җиңә алды.

100 яшькә ничек җитәргә соң? Гыйльменур әбинең ниләр ашавы, күпме йоклавы белән кызыксынабыз. Ләлә ханым әйтүенчә, каенанасының озын гомерле булуының сере яхшы уйлар белән яшәүдә.

– Әни хәсрәтләрне дә күп күргән. Сугыш кичкән хатын-кыз бит ул! Әмма сынауларда сынмаган. Һәр кешегә ачык йөзле булган. Эштән курыкмаган. Барыбызның гаиләдәге тынычлыгын саклаган кеше ул, – ди Ләлә апа. – Элек алар безне карап үстерсә, хәзер балалар әниләрне тәрбияләргә тиеш. Шөкер, Илдар белән бергә әнине җитәкләп йөртәбез. Тәмле ризыклар ашатам. Әни яңа пешкән ипи, камыр ризыкларын шулкадәр нык ярата. Баллыга исе китә. Рәхәтләнеп сыйлыйбыз. Ул озак яшәп, без исә аның хәер-догасын күбрәк ала алсак иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ЯШӘҮ ДӘВАМ ИТӘ

ЯЗУЧЫ, ЖУРНАЛИСТ РӘФИКЪ ЮНЫСНЫҢ ТУУЫНА – 80 ЕЛ

Үзе күренмичә генә кеше күрерлек олы эшләр эшләп калдырган шәхес. Рухи халәткә төгәл бәя бирә алган фикер иясе. Зәвыклы шагыйрь. Елъязмачы. Фидакарь хезмәт үрнәге. Болар барысы да – Рәфикъ Юныс турында. Аның кебек башка кеше юк, диләр. Шулайдыр. Милләт дип янып, зур хезмәтләр калдырган кешенең зур исем-дәрәҗәләре дә юк икән бит. Бу да – аның олы шәхес булуына дәлилдер.

Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин яшьтәшен аның кебек фидакарьләр бүтән булмас инде, дип искә алды:

– Рәфикъ Юныс – минем өчен бик кадерле кеше. Беренчедән, ул – минем яшьтәшем. 1960 елны бергә абитуриент булып башта Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кердек. Авырлык белән, чөнки ул вакытта югары уку йортына керү өчен хезмәт стажы кирәк иде. Без исә – мәктәпне әле генә тәмамлаган егетләр. Шулай да керә алдык. Менә шуннан бирле аның вафатына кадәр аралашып яшәдек. Ул миңа кадерле, чөнки намуслы, ихлас, шул ук вакытта җаваплылык белән эшли торган, пөхтә, бөртекчән, үзенә бик таләпчән кеше иде. Шагыйрь буларак та, публицист буларак та аңа хөрмәтем зур. 1990 нчы елларда публицистик әсәрләр һәм публицистик шигырьләр язып, халыкның милли уянып уяту юнәлешендә үзеннән өлеш кертте. Аның белән бергә зур эш эшләп калдык, шуңа да сөенәм. «Казан утлары» журналының меңенче саны чыгу уңаеннан «Сүнмәс утлар балкышы» дигән зур китап әзерләдек. Мин шефлык итсәм, ул төп башкаручысы булды. Үткәннәр сагындыра, чөнки үзенең журналистлык, язучылык эшенә фанатик рәвештә бирелгән кешеләр хәзер инде бик күп түгел. Безнең буын бу җәһәттән фидакарь хезмәт үрнәге булды.



«Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин үзен Рәфикъ Юныс мәктәбен узган кеше дип атады:

– Аның белән мине бер якынлык, җылылык җепләре тоташтырып тора сыман иде. Беренчедән, без аның белән ике тапкыр «Казан утлары» журналында бергә эшләдек. 2010 елда мин «Казан утлары» журналына бүлек мөхәррире булып килгәндә, Рәфикъ абый баш мөхәррир урынбасары иде. Ә инде мин журналга баш мөхәррир булып килгән вакытта ул бүлек мөхәррире булып эшли иде. Икенчедән, без Рәфикъ абый белән якташлар, икебез дә Арча районыннан, туган авыллларыбыз ызандашлар. Тагын бер нәрсә бар: Рәфикъ абый нәселендә дә, минем нәселдә дә бабайлар мулла булган. Безнең якларга 1700 нче елларда Казаннан берничә гаилә күченеп кайта. Шуның берише – Кәчедә, кайберләре Наласада төпләнә. Шуңа күрә без аның белән, бәлкем әле без туганнардыр, дип тә сөйләшә идек. Рәфикъ абый «Казан утлары»на эшкә килгәч, миңа игътибарлы булды. Мин эшләгән мәкаләләрне, язмаларны хәйран гына «кызартып» редакцияли торган иде. Үземне дә кызартырлык итеп тиргәп тә ала иде. Бу инде – яшь егет эшкә өйрәнсен, аннан яхшы мөхәррир чыксын дип эшләнгән эш. Хәзер мин аны тагын да ныграк аңлыйм, ул вакытта да рәхмәт әйтә идем. Бу җәһәттән аның мәктәбен үттем, дип әйтә алам. «Казан утлары»ннан «Идел»гә күчкәндә Рәфикъ абый, бер яктан, сөенде, чөнки яшьләр журналы аның үзенә дә кадерле, ул – анда эшләгән, әлеге басманы булдыру өчен күп көч салган кеше. Икенче яктан, көенде дә, чөнки ул мине, мөгаен, үзенә алмаш, эш аты итеп күргән булгандыр. Ә инде эшли башлагач, янымa килеп утыра, уңышларга сөенә торган булды.

Рәфикъ абый – милләтпәрвәр шәхес. Ул җаны-тәне белән милләт өчен янып йөрде, татар теленең хәленә борчылды, милли чараларның берсен дә калдырмады. Берничә тапкыр урам җыенына бергә дә барган булды. Аның «Татарстан референдумы» дигән китабы да – ничек борчылып яшәвенә дәлил. Аннан соң ул – фанатик кеше. Эшенә җаны-тәне белән бирелгән, «Казан утлары»нда куна-төнә эшләде дисәң дә, арттыру булмас. Андый кешеләрне табу хәзер мөмкин дә түгел инде.

> Ихлас иде. Самимилек, сабыйлык бар иде анда һәрвакытта да. Эчендә мәкерлек булмагандыр. Шуңа аны редакциядә дә чын күңелдән яраталар иде. 75 яшен тутыргач көнне эштән китте, ләкин һич кенә дә безнең арадан китмәде. Килеп йөри иде, ишектән керә-керешкә, ишеттеңме, әле генә хәбәр иттеләр, дип сүз башлый. «Нәрсә булган?» – дисең. «Яшәү давам итә!» – ди. Шул сүзе белән проблемаларны юкка чыгара торган иде. Юкса күпме тапкыр кабатланган, шулай әйтәсен дә беләсең, әмма шул сүзне көтеп торасың.

Үзенчәлекле кеше иде. Сәламәт яшәү рәвеше алып барды, гел җәяү йөрде, 10 нчы катка лифт белән күтәрелгәнен күргәнем булмады. Кабере дә үзе кебек матур бер үзенчәлекле җирдә, бабалары янәшәсендә. Форсат булганда, Рәфикъ абый янына кереп чыгарга тырышам. Зиратка еш керәм, дөресен әйткәндә, чөнки ул миңа гомеренең азагына чаклы игътибарлы өлкән ага булды.

Көндәлә бер канәгатьсезлек хисе калды. Ул гомеренең соңгы елларында «Казан утлары»ның 100 еллыгына дип китап әзерли башлаган иде. «Сүнмәс утлар балкышы»н тулысынча диярлек Рәфикъ абый эшләп чыккан иде бит. Бусы – шуның тулы варианты булырга тиеш иде. Эштән киткәч тә, әлеге китап белән көнтөн мәш килде, редакциягә дә еш кына килә, архивларны барлый иде. Нәтиҗәдә 6–7 папка туплады, әмма хезмәтен тәмамлый алмады. Мин инде аны 100 еллыкка чыгарырга ниятләгән дә идем. Ләкин ул икенче көнне, тагын өстәргә кирәк әле, дип алып китеп барды. Шулай итеп ул папкаларны ахыргача тапшырып бетерә алмады. Аннары бу эштә үзеннән башка очына чыгарлык та түгел иде инде.

Татарстанның халык шагыйре Гәзинур Морат өчен ул – барыннан да бигрәк елъязмачы:

– Рәфикъ Юныс шәп шагыйрь дә, кыю һәм җеген җеккә китереп яза белүче публицист та иде. Ә инде «Татарстан референдумы» дигән китабына килсәк, ул – шул чорны чагылдырган, фактик материалларны туплап биргән документаль хезмәт. Татарстан референдумының ничек узуын, нинди вакытка туры килүен, Мәскәү, җирле түрәләр, судья-прокурорларның үзен ничек тотуын, нәрсә сөйләвен күзалларга теләсәң, шушы китапны укырга кирәк. Бу китап чыгу белән таралып та бетте, аның бәһасен аңлаган кеше бик яхшы аңлады. Гадәттә мондый китаплар авыр тел белән, рәсми языла. Рәфикъның исә монда шагыйрьлеге сизелә, ул вакыйгаларны мавыктыргыч итеп бирә белгән. Бу – киләчәк буынга да кызык булган, гасырларга кала торган документ, безнең тарих.

Шагыйрә Асия Юнысова 40 ел бергә гомер кичергән ирен бала җанлы иде дип искә алды:

– Рәфикъ гаиләдә җәйлы кеше түгел иде, мин аның сәбәбен ятимлектә үсүендә күрдем. Әнисеннән – 10, әтисеннән 15 яшендә ятим калган. Ул – иң кече бала, иң олы абыйсы белән яшь аермасы – 23 ел, бу бик зур аерма бит инде. Аларның бөтенесе дә аны кайгыртып яшәгән. Мөгаен, шуңа ул үзен һәрвакыт хаклы дип уйлаган, ахры. Дөрес, ул бик акыллы бала булган, мәктәпне көмеш медальгә тәмамлаган, үзен һәр яктан үстерергә тырышкан. Китаплар күп укыган һәм укый иде. Дуслары белән дә үзен лидер позициясендә тота, аныңча булмаса, упкәли торган гадәте бар иде. Шуңа күрә алар аның җаенда тордылар. Менә бу гаиләдә дә аның авыр сыйфаты иде. Рәфикъ әйбәт әти, оныгына әйбәт бабай булды. Бала белән уйнарга чыгып китәләр, ике бала кебек кайтып керәләр иде. «Нишләп бала белән чынлап уйныйсың, азрак юл куймыйсың соң?» – дигәч, чынлап уйнамагач, уйнамыйм да мин аны, дип әйтә иде. Балалар аны ярата иде, бәлкем аларның дөньясына якын булганга күрәдер. Ә иҗатта, бер гаиләдә ике шагыйрь, ике язучы була алмый дип карый иде кебек. Ләкин мин яңадан язып киткәч, ул минем мөмкинлекләрне таныды. Иҗатымны күзәтеп барды. Үзенең иҗаты ихлас, фальшьлардан азат, гадел булды. Бик авырдан яза, язганнары саллы иде. Ул минем белән җитди темаларга сөйләшергә яратты. Бервакыт: «Синнән теләсә нинди җыелышларга караганда да күбрәк мәгълүмат алам бит мин», – дип әйтте.

Соңгы елларда Рәфикъ Юныс Дания Шәрипова белән гомер кичерде. Хатыны аның хакында, мине яхшы якка үзгәртте, дип сөйләде:

– Рәфикъ минем өчен генә түгел, бик күпләр өчен бик әйбәт кеше булды. Мин аны баштарак аңламадым, тора-бара гына төшендем. Эче тулы яхшылык иде, бервакытта да беркемгә дә каты бәрелмәде. Баштарак кайбер гамәлләрен сәерлек дип кабул итсәм, үзен белә башлагач, аның бер самимилек, сафлык, ихласлык билгесе икәнен төшендем. Ул көчле дә, гаярь дә, шул ук вакытта бала кебек самими дә була ала. Ул кешегә шулкадәр ышана, беркайчан да беркемдә дә мәкер булыр дип башына да китерми. Мин аның урамда үз эченнән нидер укыпып йөргәнен күргәнем бар иде. Баксаң, юлында бала очраса, аңа белгәннәрен укый, теләкләр тели торган булган икән. Киләчәкләре яхшы, илгә кирәкле кеше булсыннар дип телим, дип әйтә иде. Рәфикъ мине дә үзгәртте. Мин аны башта аңламадым, күптән түгел генә төшендем. Баксаң, хәзер аның шикелле эшлим, аның күп гамәлләрен кабатлыйм икән бит. Кызганыч, исән чакта кадерен белмәдәләр, үзе дә сер бирмәде. Әгәр телевидениегә чакырсалар, баш тартты. Үзе теләп, кулыгәдә калды. Кирәкле кешеләр мине болай да белә, дип әйтә иде.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Дәвамы.
Башы 27 гыйнвар, 3 февраль саннарында

АСИЯ ЮНЫСОВА

МАДАМ БОВАРИ

Инде үзен карасын Мәүлия. Парикмахерга йөрисе юк – табигый бөдрә чәче кемне дә кызыктырырлык. Тырнак буяп, маникюр ясап йөрүне өйрәнә алмады. Алайса нишләсен икән соң? Уйлый торгач, кичтән үк үзе мунча кереп кайтырга булды. Чиста тәннең исе тәмле. Матур халаты бар.

30 ноябрь тоташ көтүдән гыйбарәт булды. Тавык шулпасын балконга бер чыгарды, бер кертте. Бәлешкә дип тураган итен суыткычтан бер алды, бер куйды. Карават түрендә чигүле тышлык кигән мендәрләр, без әзер дигәндәй, кукраеп утыра. Ак ашъяулык җәйгән өстәл өстендәге чәчәкләр дә көтеп зарыкты. Ишек кыңгыравына кагылучы булмады да булмады. Төштән соңрак Мәүлиянең хәлиткеч көне икәнен белгән ахирәтләре телефоннан бимазалый башлады. «Юк шул», «күренми әле», «белерсез әле» кебек өтек-өтек җаваплар бирү хатынны йөдәтте. Телефонны алмаска тырышты. Тора-бара билгесезлек ачуын китерә башлады. Капка янына каршы алырга бармавына үкенеп тә куйды. Һаман горур булам дигәч тә инде...

Икенче көнне Мәүлия эшкә бик кәефсез килде. Һаман шул ук: «юк», «күренмәде», «белмим» кебек җавапларны ишеткәч, аны бүтән аптыратмадылар.

Бер атнадан, шулпалар түгелгәч, гөбәдияләр күрше-тирә белән ашалгач, ишеткән ишелеп килеп керде ул. Итәгенә аю басып карамаган бу ир-ат өммәте уйлаганы юш килмәгән хатын-кызның гел тәртәгә тибү гадәте барлыгын белми иде шул. Мәүлия киресенә каткан иде. Күрешү салкынча булды. Чишенеп, киемнәрен чөйгә элгәч, Рахман өй эчен күздән кичереп соклангандай итте:

– И-и апасы! Синең өең бик кәттә икән. «Кысан яшим», дип язган идең. Монда полный шәһәрчә муллык лабаса. Безнекеләрнең авылда телевизорлары да юк. Түбәләре кыегайган, коймалары ауган. Шуларны рәтләп, атнам үтте дә китте. Прости, синең янга кичегебрәк килдем. Но зато бөтенләйгә! – шулай дип ул, баш бармагын канәгать тырпайтып, шаркылдап көлеп җибәрде.

Мәүлия хатлар аша белгән кеше түгел иде бу. Каш, борын, авыз – шул ук. Фотодагыча. Әмма сүз төзү тәртибе хатлардагыча түгел, бүтән. Аннары кемнәр ул «безнекеләр»? Эти-әнисеме? Авылда Рахманны гаиләсе көткәнме әллә? Үзеннән алты яшькә кече икәнен белгәч, Мәүлия аны өйләнмәгән егеткә чыгарган иде. Авылда хәзер егетләр кырык яшькә кадәр буйдак йөри бит. Ике арадагы хатларда бу турыда нигәдер сүз кузгалмады. Мәүлиягә утыз сигез яшь, димәк, бу «арыслан»га әле утыз ике генә!

Кашык-тәлинкә өстәлгә менгәч, шкафтан бер матур шешә төшкәч, йөзләр ачылды. Озак кына сөйләшеп утырдылар. Күп нәрсә ачыкланды. Рахман килеп керүгә тыгынаеп калган өендә Мәүлиягә кысан ук була башлады.

Рахманның, чыннан да, хатыны белән малае бар икән. Алар икәүләшеп аны төрмә капкасы янына ук килеп каршы алганнар. «Ну мин аңа кайтмыйм. Ул сатты бит мине!» Шешәдәге сыеклык телне ача. «Сату» тарихы да мәгълүм булды. Һич тә бүрек урлаган караклар юлында ялгыш очрап тотылмаган икән Рахман.

– Дуслар кайтканые. Шашлык та шашлык, диләр. Минем үземнең сарыклар юк. Ул тинтәкләр авыл кешесендә бар да бар һәм дә бушлай дип беләләр. «Әйдә, суй инде сарыгыңны безнең хөрмәткә!» – дигәч, тагын «саран тәре!» дип тә өстәгәч, кытык килде бит, апасы. Колхоз көтүеннән бер сарыкны алдым да киттем. Сыйландык малайлар белән бик шәпләп. Өй борынча эзли башлаганнар теге малны. Минем Хәтирә тоткан да әйткән. «Зинһар өчен, тавыш куптармагыз, түлибез», – дигән. Каян килгән Алла бәндәсе. Честный! Үземне саткан, төрмәгә олактырган шул хатынны гафу итәмме мин! Так что мин синдә калам, Милашка! Кара, исемең матур икән синең.

Бөтен кич буена ишеткән беренче ягымлы сүз иде бу. «Апасы да апасы!» Яратмый Мәүлия шулай эндәшкәнне, җене сөйми. Авылы аша урап килгән Рахманны мунчага җибәреп торасы юк инде алайса. Чигүле тышлык кигәч, кунак кызы кебек күркәмләнгән мендәрләрне дә, мөгаен, ишмәс Мәүлия. Төнгә каршы куып чыгармас, әмма иртәгәсен ишеккә күрсәтер.

Ике елга сузылган хыялының чынбарлыкка әверелмичә генә чәлпәрәмә килүенә Мәүлиянең артык исе китмәде. Рахманны тиешенчә каршы алу ыгы-зыгысына бирелеп, өченче көн сыйныфташы Зәмзәмия белән сөйләшкәндә ишеткән хәбәрне колак яныннан гына үткәргән иде. Югыйсә Зәмзәмия иң мөһим хәбәрне әйткән икән бит: «Малакаем, базарда йөргәндә Тәмизне очраттым. Хатыны белән йөриләр иде. Әй, малай! Киендергән соң хатынын! Киенүен киенгән дә бит, чирли икән... Табибка күренергә дип килгәннәр Казанга. Эшләүләре һаман Себердә икән».

Мәүлиянең ике җиргә урын җәя башлаганын күргәч, Рахман кайнап чыкты:

– Ты брось. Утыз ике яшьлек ять-яшь ирләр бусагаңда аунап ята мәллә?! – Мәүлиянең каш астыннан сөзеп кенә караган күзләрендә шайтани очкыннар кабынуын күргәч, юашлана төште. – Сагындым бит мин сине. Хатларыңны укыганда бөтен барак көнләште миннән.

Хатын эсселе-суыклы булып, дертләп китте. Аның йөрәк серләре язылган хатларны бөтен барак белән бергә җыйнаулап укыганнармы?!

– Син! Ни әйткәнеңне аңлыйсыңмы? Сиңа гына язган хатлар иде ул!

– Шулай, апасы, шулай. Кызыгулары да шуңа – миңа гына язган хатлар булганга!

– Җавап язучысы да син түгел иде диярсең! – Эчке шикләнү белән әйтелгән бу сүзенең рас икәнен белгәч, Мәүлия җенле өермәгә әйләнде:

– Бар, чыгып кит. Миңа хатларны кем язган, мин шуны көтәм...

– Кызма әле, Мәүлия-җан, мин алай килештереп яза белмим бит. Шуңа күрә генә инде. Түләдем мин. Һәр хат өчен бер кап сигарет! Бик кыйммәт бәя ул анда. Йә, кил инде монда. Кочаклыйм үзеңне. Ачулану килешә үзеңә, алсуланып чыктың. Йә, бер үбим әле...

Эче-тышы ялган белән тулган бу кешенең үбүе дә, кочуы да, олы куллары белән хыялындагыча назлап, битеннән сыйпаулары да кирәк түгел иде хатынга. Китсен, күзеннән югалсын! Ике ел тормышын эчтәлекле итүенә рәхмәт анысы. Бетте, фильм тәмам. Әйе, кинодагы кебек яши шул Мәүлия – Милашка, Мадам Бовари!

Күңеленә хуш килмәгән кеше белән араны кистереп өзә белү гадәте бу юлы да ярады. Рахман шәһәр янындагы авылдан иде. Казандагы туган-тумачасын исенә төшерде. Ничек кергән – шулай җыенып, Каравай бистәсенә таба юнәлде. Кабат-кабат килер әле ул. «Синнән башка яшәр хәлем юк», – дип, Мәүлиянең алдына килеп тезләнер. Утыз ике яшьлек тап-таза ир-егетнең Мәүлия кебек яшьлеге узган хатынга кирәкмәвен аңлый алмый интегер. Ни кирәк соң бу хатынга? Әйтте бит, авылга кайтмыйм, сине генә яратырмын, диде. Ә ул куа, кабул итми. Аптыраш, билләһи.

Икенче көнне Мәүлиянең эштән кайтуына Рахман бусагада утыра.

– Йөрәгемә урын таба алмыйм. Бармадым мин җизниләргә. Төрмәдән чыктым әле дип, ничек барып керәсең. – Карасана, намус әсәре бар икән үзеңдә. – Бомжга әйләнү озак түгел икән.

Мәүлия ул урам сукбайларын кызгана, һәркайсының бер каргалган язмышы бардыр инде, дип уйлый торган иде. Инде менә чиратка басканы үз бусагасында җирәбәгә ни язганын көтеп утыра. Хатын ишекне дәшми генә ачты. Кыяр-кыймас ияреп кергән Рахманга ни актан, ни карадан бер сүз әйтмәде. Чәен куйды, ашын җылытты.

– Нигә мескенләнәсең, дустым. Синең бит өең, гаиләң бар. Хәзер олы-олы түрәләр дә авылга кайтып, кыйшаеп беткән өйләр сатып ала. Авыл һавасына, җирдә казынуга кызыга, – диде ул, ниһаять.

– Анда син юк, Мәүлия-җан. Өч ел буе язган хатларыңны укып, җаным белән беректем мин сиңа. Бер атна торып килдем бит инде. Ябышмас миңа андагы тормыш. Син кертмәсәң дә, китмим мин анда. Хатларыңда язган идең бит, өй салырбыз, дип. Салам. Үзем эшлим бөтенесен, Мәүлия-җан. Челтәр бизәкле итеп. Кызыбыз да туар. Кума мине... Әйдә, бер генә кич булса да, йоклап карыйк. Күкрәгемә кысыйм сине, – Рахман хатларындагы кебек сөйли иде. Аек баштан акылы гына күренә бит әле бу!

Мәүлия урынны бергә җәйде. Яңгыр көткән иген басуы кебек, наз тансыклап коргаксыган хисияте бер кинәнергә тиештер бит инде ләбаса! Бу төн әллә булды, әллә юк. Аңламассың. Хыял диңгезенә кереп югалмаган бу төне, әйтерсең лә, чын түгел, төш булгандыр. Иркәли белә икән Рахман. Мәүлия ишетергә зарыккан сүзләрне дә тапты. Иртәгәсен алар татуланып уяндылар. Ләкин беренче очрашудагы шикле күләгәләр якында гына йөри иде әле. Бер алдаган гел алдар. Гаиләсен ташлаган кеше сине дә ташлар... Рахман хәзер Казанда эш эзләп карар. Урнашыр. Җизниләрендә яисә, җае чыкса, тулай торакта яшәп торыр. Ике ай чамасы Мәүлиядә күренмәс. Янәмәсе, сынау вакыты узар. Сынау хакында йөзенә бәреп әйтмәде хатын. «Улым ике айга каникулга кайта. Килеп йөрмәсәң, яхшы булыр иде», – дигәнрәк матур хәйлә тапты. Кыш уртасында нинди ике айлык каникул инде югыйсә. Рахман килеште. Шулай аерылыштылар.

Яңа ел алдыннанрак Оренбургтагы дус хатыны килеп төште. Зөлфә шулай ел да бер урый. Шәлләр тәэп килә. Төрле оешмаларга кереп сата. Яшәве Мәүлиядә була. Килгән саен берәр матур шәл бүләк итеп китә. Бу юлы да әйбәт кенә сату итте Зөлфә. Әмма беркадәр шәлләре үтмәде. Мәүлия сирәк күренгән дустына Рахман тарихын сөйләде, әлбәттә. «Нишләп йөри микән?» – диештеләр. «Бер дә бүтән түгелдер әле, хатыны янына кыяклагандыр. Казанда булса, чуар ир йөрәге түзмәс, Мәүлиянең юлына биш чыгар иде. Көнләшеп булса да, күзәтер иде, – диде Зөлфә. – Авылы якын гына дисең бит. Әйдә, шәл саткан булып, урамнарыннан бер урап кайтыйк. Җайлап кына белешербез. Партизаннар кебек».

Партизанлык ярады. Капка төбендә кар көрәп йөрүче беренче очраган малайдан ук Рахман Фәйзетдиновлар өен сорадылар:

– Минем әти ул – Рахман Фәйзетдинов. Бәй, менә безнең өй. Әти эштә. Ул хәзер газовик булып йөри. Газ баллоннары тарата.

– Юк, наным, әтиең кирәкми безгә, шәл сатабыз. Әниең өйдәдер?

Малайның әнисе укытучы икән. Ул да мәктәптә. Өйгә кереп торасы булмаганга сөенделәр генә. Аның каруы мәктәпкә кагылып, ике-өч нәзек шәл сатып чыктылар. Челтәр-шарфның берсен Хәтирә алды. Юка гәүдәле чандыр гына хатын икән Рахманның хәләле. Шарфны аңа Зөлфә юнь бәягә бирде. Кардәш кебек бит инде.

Бая әйткән тезләнүләр булды булуын, әмма Мәүлия хәзер чакматаштан катырак иде.

«Төрмә кошы» вакыйгасыннан соң Мәүлия боегып калды. Әмма сынатмады. «Әйттем мин сезгә. Кайтып күренгәнче генә кирәк ул миңа дип. Миңа ир кирәк түгел. Кемгә кирәк – шул асрасын». «Асрасын» сүзенә юри басым ясады. Эштәге хатыннар каршы дәшмәде. Һәркемнең өендә үз ире – чире бар шул. Тоткасыз чемоданы. Тотып йөрергә җайсыз, ташлап калдырырга җәл булганы.

Тәмизнең хатыны үлү турындагы хәбәр Рахман вакыйгасын тиз оныттырды. Һаман шул, бөтенесен алдан белүче саескан Зәмзәмия ирештерде бу хәбәрне. «Шалтыратып кайгысын уртаклаштым. Миндә мобильнигының номеры бар. Син дә язып ал. Хәлен белерсең. Авылдаш бит. Чит җирдә ят кешегә бик кирәк түгел аның хәсрәте. Ә без уртаклашыйк кайгысын. И җәл инде ул. Кырык яшендә ике бала белән ялгыз калсын әле ир кеше. Шылтырат син дә, ташламыйлар, дип юансын, ичмаса».

Көне-сәгате белән кыймады Мәүлия, бер айлап вакыт үткәч кенә шылтыратты. Ашыкмавы яраган икән. Тәмиз иркенләп сөйләште. Казанга юл төшсә, керермен, диде. Әле башы каткан чагы икән. Балалар зур инде, өлкән сыйныфта укыйлар, ди. Игезәкләр. Ике елдан аларны укырга урнаштыру хәстәренә керешәсе булыр, ди. Институтка Казанга кодалыйм, ди.

Тәмизнең газиз тавышын ишетүнең рәхәтлеге! Сөйләшүе дә һаман шулай риясыз. Ялган вәгъдә бирмәс, буш сүз сөйләмәс. Тәмиз, Тәмиз – чиста дигән сүз икән ул. Төркиядәге улының теленә шул мәгънә белән кергән инде тәмиз. Мәүлия дә, җае белән, бу сүзне әйләнешкә кертте. «Янәсе, бу сөлге бик тәмиз», я «бу су тәмиз күренә». Күңелгә якын кешенең исемен кабатлап йөрү өчен нинди матур юл тапты!

Тәмиз белән сөйләшүдән соң ике еллап вакыт үтте. Өйләнде микән? Шылтыратканы булмады. Мәүлия үзе кыймады. Егет армиядә чагында күңел хисләрен сиздереп, бер авызы пешкән иде бит инде.

Трамвай йөртүченең Мәүлия кулына кагылган җылы кулы әле һаман да булса очкын көтеп яткан тырбызык шикелле мәхәббәткә сусаган күңелне дөрләтеп җибәрде. «Их, йөрәгеңне шушы учка саласы иде!» – дип уйлады ул, трамвайдан төшеп калгач. Рельслар буйлап тырт-тырт китеп барган сары трамвай аңа бик якын булып тоелды. Номерын хәтерләп калды.

Ахыры бар >

ТОРМЫШ – ОРМЫШ

Тормышымның яктылыгын бераз киметтем. Зарядкасы кичкә кадәр җитсен дип.

Элек ял көннәре: берәрсе шалтыратсын да берәр кая чакырсын иде, дип телисең.

Хәзер ял көннәре: берәрсе шалтыратып, берәр кая чакыра гына күрмәсен иде, дип телисең.

Олыгайган саен кешеләрне ике төркемгә бүлә башладым: «Нигә мин сезгә?» һәм «Сез миңа нигә?»

Ни өчен табиблар тәмле ризыкларны зыянлы дип исбатлый? Чөнки халык тук һәм канәгать булса, табибларга йөрми башлаячак.

Салмак кына каһвә эчеп утырам. Пальма һәм диңгез дулкыннарын күзәтәм. Ни дисәң дә, фотообойларны сайлый белеп сайларга кирәк шул.

Чәнти бармакның нигә кирәк икәнен балык ашап утырганда смс килгәч кенә аңлыйсың.

– Тормышны аңлар өчен ике ай буе телевизор карадым.
– Һәм?
– Белгәнемнән дә әзрәк аңлый башладым бугай хәзер.

Әз-мәз мәзәк

Әгәр дә 23 февраль көнне ир-ат үзенә оекбаш сатып ала икән, кызлар, игътибар итегез: бу егет өйләнмәгән.

* * *

– Ни өчен Малевичның кара шакмагына бөтен кеше шакката, ә геометрия дәресләренә битараф?

* * *

– Кәрим, син Илдарны аңгыра дип әйттеңме?
– Юк. «Бөтен аңгыралар бер сафка тезелегез, ә син, Илдар, барабан тотып, сафны җитәкләү», – дидем.

* * *

Тычканнан куркып сикергән хатын-кыз арыслан өстенә менеп атлана ала.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Сая, лəтчə, хак, əкрен, əле, Кəрəкəс, авылдаш, ай, шалт, Ира, Əбрар, ОРЗ, ыгы, май, Сталин, əдəп, арфа, Вена, арзан, Би, Ка, анар, Тонк, колли, бура, будуар, Дархан, хор, ерак, казак, лайв, Рог, аргамак, Кос, тəлинкə.

Вертикаль: Аида, Əлбəдəн, Абра, Аспарух, карт, рак, Илгəрəй, ана, олпат, зəркəн, старт, Шри, Норма, гол, казна, Красин, Сəхнə, РБК, Ом, Латыйфи, болгарка, Яркəев, кура, ырым, код, Валуев, димче, лар, ара, Иран, шайтан.

Финишның чишмә башы | Хәния җырлаган елга | Әдәби журнал | Йонлач җанвар | Дәрес | Язучы Флүс ... | Тиз түгел | Бая | Әндри банкы | Бер саланыкы | Зәй районы авылы | Питрәчтә хәрби уеннар | Ул күрде, кояш алды | Мәшһүр | ...-зыгы | «Волга-Волга» җыры | Салкын тию чире | ..., Мөхәммәтҗан! | Авызыңа бал да шул | Галим ... Кәримуллин | Кубрат хан улы | Кыллы уен коралы | ...-шырым | «Пикапер» апа | ...-тирә | Виссарионыч | ...-коры | ...-Ланка | Австрия башкаласы | ...-әхлак | Филиппин елгасы | «-2» рок төркеме | «Форд» төре | Әрҗә | Тәһран иле | Зур ташламалы | Йорт «скелеты» | Эшлекле рус матбугат чарасы | Денсез котыртучы | Гранат чәчәге | Кәрт уены | Җырчылар төркеме | Хатын-кыз бүлмәсе | Эт токымы | Ювелир татарча | Балтач районы авылы | Домофонда җыябыз | Монголиядәге шәһәр | Өч хәрефле авыру | Папаха кигән Дон абзые | Тере концерт | Шундый араны якын итеп | Ата-... | Кривой ... шәһәре | ... җиләге тәме | Грек утравы | Алман физигы | Җитез ат | Гомер буе ... тотып | Роналду кертте | Элекке Япеев урамы | Электр тимер кискеч

Беләсең килсә...

1 Бу ил Берләшкән Милләтләр Оешмасына керми:
а) Мальта;
б) Ватикан;
в) Лихтенштейн.

2 «Бәрмәнчек» ансамблен кем җитәкли?
а) Артур Поляков;
б) Геннадий Макаров;
в) Виталий Агапов.

3 «Хакуна матата» сүзе нәрсәне аңлата?
а) Әйдәгез, алга!
б) Бер дә борчылмагыз!
в) Сау булыгыз!

4 Классик пианиноның ничә клавишы бар?
а) 80;
б) 86;
в) 88.

Җаваплар: 1.б); 2.а); 3.б); 4.в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15281 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 230

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+